**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**

**МБГББУ “Сарман гимназиясе”**

# МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучыларының үрнәк авторлык программалары җыентыгы

**(туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары,**

**сыйныф җитәкчеләре өчен кулланма)**

**Сарман-2023**

## Төзүчеләр:

1. Гарипова М.И. – МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең укыту методик эшләр буенча директор урынбасары

2. Матзянова Р.Г. – МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, методик берләшмә җитәкчесе, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

3. Салихова А.Н. – МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

4. Арсланова Г.М. – МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

5. Ханова Н.В. – МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Үрнәк программалар **Минһаҗева Л.И**. - филология фәннәре кандидаты, КФУның татар әдәбияты һәм тарихы кафедрасы доценты; **Сибгаева Ф.Р. -** филология фәннәре кандидаты, КФУның гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты; **Даутов Г. Ф. -** филология фәннәре кандидаты, КФУның Алабуга филиалы доценты; **Галлямов Ф. Г. -** филология фәннәре профессоры, КФУның Алабуга филиалы доценты тарафыннан рецензияләнгән.

**Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары, сыйныф җитәкчеләре өчен кулланма: Сарман, 2023, - 47 б.**

# **УКУЧЫЛАРНЫҢ СӘЛӘТЛӘРЕН АЧЫКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ**

*МБББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Салихова Алсу Нисбәт кызы*

“Яшь талантларның беренче авазларын мәктәп залларыннан башлап ишетерсез. Дөньяга сирәк килә торган Тукайларның яшьлеге сезнең кулда”.

С. Хәким

**Аңлатма язуы**

Татар теле һәм әдәбиятыннан өстәмә белем бирү, кагыйдә буларак, дәресләрдән соң уздырыла һәм анда балаларның татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынуларын үстерү, аңа мәхәббәт тәрбияләү бурычлары куела. Тәкъдим ителә торган эксперименталь проект буенча балалар белән эшне түгәрәкләрдә, клубларда оештырырга була. Монда олимпиадага әзерләнүче, татар халкы һәм төбәк тарихын, аның бай мирасын өйрәнергә теләгән балалар йөри. Бу программа укучыларда тирән белемнәр белән беррәттән җаваплылык хисе тәрбияләү, бер-береңә игътибарлы булуны, үз гаиләң, нәселеңнең күренекле кешеләре, төбәк тарихы, аның фольклоры белән кызыксынуны, шулай ук укучыларның табигый сәләтләрен үстерүне,фәнни-тикшеренү эшенең нечкәлекләрен өйрәтүне күздә тота.
Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз. Ә ул үз чиратында , туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш.Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар телеңне, үзеңнең туган ягыңны, аның тарихын, кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала. Кеше яшьтән үк яхшы белән начарны, түбәнлек белән бөеклекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш. Бүгенге көн мәктәбе алдына сәләтле һәм талантлы балаларны укыту һәм тәрбияләү системасын булдыру; һәр укучының сәләтен үстерергә мөмкинлек бирә торган гамәли чаралар әзерләү максаты куела. Һәр баланың нинди дә булса сәләте бар, мин шул өлкәне табып балага талантын күрсәтү өчен шартлар тудырырга тырышам. Һәр баланың төп кызыксынуын истә тотып, белем алу өчен шартлар тудырыла, иптәшләре белән тыныч мөгамәлә һәм үзара дуслык урнаштырыла. Беренче чиратта, һәр укучы үзен кабатланмас шәхес итеп тоярга, үзенең мөмкинлекләрен, зш – гамәлләрен аңларга һәм бәяләргә тиеш.Укучылар өчен конкурслар, бәйге-ярышлар, фәнни-гамәли конференцияләр, олимпиадалар оештырыла. Укучыларның ни дәрәҗәдә белемле булуын, иң сәләтлеләрен ачыклау максатыннан төрле фәннәрдән олимпиадалар уздыру матур традициягә әверелде. Олимпиадага әзерләнү һәм анда катнашу белем алуда зур әһәмияткә ия. Чөнки олимпиадалар укучыларның танып белү активлыгын камилләштерергә һәм үстерергә, фәнни-популяр һәм башка төр өстәмә әдәбият белән җентекләп эшли белергә ярдәм итә. Бәйге-ярышларда катнашу тырышлык, максатка омтылучанлык, мөстәкыйль фикер йөртә белү кебек мөһим шәхси сыйфатлар тәрбияләргә дә булыша. Сәләтле балалар белән эшләгәндә, яңа мәгълүмати технологияләрдән файдаланып, аерым эш планы булдырырга, балаларга иҗади биремнәр әзерләргә һәм мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр системасын булдырырга кирәк. Укытучы үзе дә, балалар да иҗади эзләнергә тиеш. Шул максаттан чыгып мин дәресләрдә 6 нче сыйныфтан башлап иҗади биремнәргә, мөстәкыйль эшләргә зур игътибар бирәм. Көндәлек дәрес планнарын компьютерда җыеп, сәләтле балалар өчен аерым биремнәр,

күнегүләрне туплап, тамгалап барам. Дәрестә үтелгән материал буенча, барлык укучыларга да сәләтенә карап, төрле катлаулылыктагы күнегүләр, иҗади эшләр вакытында өстәмә биремнәр бирәм. эшләре. Әкренләп укучылар катлаулырак эзләнү эшләренә тартылалар. Иншалар, докладлар, мәкаләләр, иҗади һәм фәнни эзләнү эшләрен укучылар бик теләп язалар, иҗат итәләр. Татар теле, әдәбияты атналыкларында теләп катнашалар. Укучылар белән эшләү өчен, әлбәттә, гамәлдәге дәреслекләр генә җитми, бик күп өстәмә материал, электрон дәреслекләр таләп ителә. Укытучыга фәнни-популяр журналлардагы язмалар, архив, музей материаллары белән даими танышып барырга кирәк. Шулай ук интернет та зур ярдәм итә. Сәләтле балалар белән эшләгәндә кулланыла торган әдәбиятнең кыскача исемлеген тәкъдим итәм, үзем эш тәҗрибәмдә күбрәк шуларга таянам. Безнең республикада нинди генә кыенлыклар булса да, талантлы, сәләтле балалар беркайчан да читтә калмый. Без дә мәктәптә укучыларга уңышка ирешү һәм иҗат итү өчен шартлар тудырырга тырышабыз. Һәр укучының дөньяга, фәнгә, мәдәниятка үз ачкычын табуы мөһим. Бары тик сәләтле балалар белән эшләгәндә генә укытучы үзе дә күп нәрсәгә өйрәнә, белемен тирәнәйтә.

**Программаның максаты**

1. Уртак иҗади эшчәнлек оештыру
2. Укучыларның шәхси кызыксынуларын, сәләтләрен һәм теләкләрен ачыклау
3. Катлаулы максатка ирешү идеясе булдыру
4. Кызыксыну мотивациясен үстерү, образлы фикерләүне формалаштыру
5. Үзоештыру һәм үзфикерләү күнекмәсе булдыру.

**Бурычлар**

1. Әхлак кагыйдәләрен формалаштыру
2. Гаиләң, халкың тарихы белән кызыксыну уяту, гореф-гадәтләргә хөрмәт тәрбияләү
3. Гаилә шәҗәрәсе төзү, нәселең белән горурлык хисе тәрбияләү
4. Гомуммәдәни белем дәрәҗәсен күтәрү
5. Кирәкле Өстәмә һәм архив материаллар белән эш
6. иҗтимагый материал сайлый белү күнекмәләрен булдыру
7. Текст һәм фәнни әдәбият белән эшләү күнекмәләре тәрбияләү
8. Проблемаларның актуальлеге турында фикерләрне исбатлау күнекмәләре булдыру
9. Сөйләм эстетикасын һәм нормаларын өйрәнү

**Эшне оештыру ысуллары**

- Әзерлек этабы-актуаль тема сайлау, максат кую, эшнең формасын билгеләү, план төзү
- Әдәби аналогияләр һәм тарихи фактлар эзләү
- Кирәкле материалны җыю һәм анализлау
- эшкә Эзләнү-тикшеренү эшләренең теориясе, методикасы, таләпләр белән танышу
- Эшне яклауга әзерлек, кулланылган әдәбиятка күзәтү анализ, чагыштыру, нәтиҗә ясау күнекмәләре булдыру


### Сәләтле балалар белән эшнең схемасы




**Көтелгән нәтиҗәләр**

- Укуга уңай мөнәсәбәт
- Әйләнә-тирә дөнья белән кызыксыну
- Актив тормыш позициясе
- Иҗади мөстәкыйльлек һәм фәнни эшкә кызыксыну
- Коллектив хезмәт күнекмәләре

### Эшнең эзлеклелеге



***Проектны тормышка ашыру юллары***

Сәләтле балалар белән эшләү системасында олимпиадаларга әзерләнү аерым урын алып тора.Укучыларны олимпиадаларга әзерләү максатыннан өстәмә дәресләр үткәрү, махсус курслар укыту мөһим. Бу алымнар укучыларны бердәм дәүләт имтиханнарына һәм югары уку йортларына керү имтиханнарына әзерләүне күздә тоткан электив курсларны да үз эченә ала.

Укучыларның иҗади һәм фәнгә булган сәләтләрен ачу һәм үстерү эше төп юнәлешләре:

-фән буенча белемнәрне арттыру, мәгълүмати, коммуникатив хәбәрдарлык, дөньяга фәнни караш булдыру;

-эшчәнлекнең төрле формаларын булдыру һәм аларны сынап карау;

-эшнең конструктив-интелектуаль мохитен булдыру;

-фән олимпиадалары системасын укучыларның уку эшчәнлеген оештыруда мотивация буларак файдалану;

Сәләтле балалар белән эшләүнең тагын бер юнәлеше – укучыларның фәнни һәм эзләнү-тикшеренү эшенә сәләтләрен ачу.

Балалар мөстәкыйль рәвештә документаль  чыганакларны өйрәнеп, тикшеренү эшләре алып барырга омтылалар. Тикшеренү эшләре укытучы җитәкчелегендә алып барыла.  Эшне оештырган укытучының үзенә дә, беренчедән, төп чыганакларны белү мәҗбүри. Икенчедән, үзе дә тикшеренү эше белән шөгыльләнергә, укучының эше белән кызыксынырга тиеш.

Әзерлек этабы-актуаль тема сайлау, максат кую, эшнең формасын билгеләү, план төзүдән башлана. Әдәби аналогияләр һәм тарихи фактлар эзләү  - укучыларны эзләнү эшенә тартуның мөһим этабы. Кирәкле материалны җыю һәм анализлауга өйрәтү төп максатларның берсе булып тора. Эзләнү-тикшеренү эше мондый төр эшләрнең теориясен, методикасын өйрәнү, таләпләр белән танышудан башлана.

Эшне яклауга әзерлек, гипотезалар билгеләү, материалны системага салу, кулланылган әдәбиятка күзәтү, бәя бирә белү – эш барышында булдырыла торган күнекмәләр.

Фәнни –эзләнү эшен планлаштыру барышында киңәшләшү, иҗади эшне фәнни берләшмәдә яки төрле дәрәҗәдәге фәнни-гамәли конференцияләрдә яклар алдыннан фикер алышу балаларда үз-үзеңне тоту, аралашу культурасы тәрбияли. Яшь кеше үзен җәмгыятьнең бер өлеше итеп сизә һәм аның закон нормаларына буйсыну кирәклеген аңлый.

Өстәмә эшчәнлек аша укучыда заманча яшәеш таләпләренә җавап бирә торган сыйфатлар тәрбияләнә, бу үз чиратында яшьләрнең теге яки бу һөнәри даирәгә җиңел яраклашуына, үз сәләт һәм мөмкинлекләренә гадел бәя бирә алучы шәхес булып җитлегүенә уңай йогынты ясый.

***Куллану өчен әдәбият***


1. Мәгариф” журналлары: №6,1999; №12, 1999; №12, 2000; №4, 2001; №8, 2001; №5, 2001; №2,2004,№7,№8, 2005; №7, 2006; №2,11, 2007; №2, 2008 №1.
2. Зәкиев М.З. “Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе” Казан, 1984
3. Татар грамматикасы. 3нче том. Синтаксис. Мәскәү. Казан. ”Инсан”, “Фикер”, 1999.
4. Вәлиева Ф.С., Сатаров Г.Ф.. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Казан: Раннур, 2000
5. Сафиуллина Ф.С.. Хәзерге татар әдәби теле – Казан. Мәгариф, 2002

# ФӘННИ – ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕН ЯЗУ

## (Укытучылар һәм укучылар өчен методик кулланма)

*МБГББУ "Сарман гимназиясе"нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәтҗанова Раушания Гаяз кызы*

### Аңлатма язуы

Хәзерге мәгариф системасында укытучылардан укучыларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеген даими, системалы оештыру сорала.

Фәнни-тикшеренү эшенең четерекле мәсьәләләрен чишү бүгенгесе көндә педагоглар алдына профессиональ бурыч буларак куела.

Әлеге позиция Россия Федерация мәгарифенең милли доктринасында да чагылыш таба. Хәзерге вакытта педагоглар аттестация үткәндә дә, квалификацион категория алганда да таләп ителә.

Бүгенге педагогларның бурычы – укучыларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыру, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен ныгыту, мөстәкыйль рәвештә тикшеренү бурычларын, мәсьәләләрен куярга һәм чишәргә өйрәтү,
сәләтле укучыларны ачыклау, фәнни белемнәрне актуальләштерү һәм тирәнәйтү, танып белү активлыгына, фәнни стильдә фикер йөртү эшчәнлегенә ия булган иҗади шәхес тәрбияләү.

Укучыларны фән дөньясына алып керү, кызыксындыру, аларны тикшеренү эшләренә җәлеп итү проблемасы һәр укытучыны уйландыра. Беренчедән, мондый укучылар китапларны күпләп укый башлыйлар, чөнки әдәби әсәр аның эзләнү эшендә төп чыганак булып хезмәт итә. Укучы китап авторының башка әсәрләрен алып укый, чагыштыра, бу темага язылган башка авторларның да хезмәтләрен, әсәрләрен эзли, иҗади фикерли.

Икенчедән, укучының төрле сүзлек, тәнкыйди материаллар белән эшләү күнекмәсе арта. Укучыларда мондый күнекмәләр булдыруга игътибарны көчәйтергә кирәклеге ачык. Торган саен күбәя барган фәнни мәгълүмат эзлекле рәвештә эшли белүне таләп итә.

Эшне башкару барышында кайбер укучыларда киләчәктә фән дөньясын ныклап үзләштерү теләге уяну ихтималын да күз алдыннан югалтырга ярамый. Дәресләребездә утыручы егет һәм кызлар арасында киләсе көн галимнәре дә утырырга мөмкин бит.

Хәзерге җәмгыять өчен укучыларның төрле фәннәрдән тирән белемле булуы гына җитми. Аларның мәктәп программасының база курсын ныклап үзләштергән дигәне дә алган белемен таныш шартларда гына куллана белә, көтелмәгән хәлләр килеп туганда иҗади фикерли, яңа идеяләр белән яши, мөстәкыйль эш итә алмый. Шуңа да әзер белемнәрне үзләштерүдән һәр укучының мөмкинлеген һәм үзенчәлеген күздә тоткан мөстәкыйль танып белү эшчәнлеге дәрәҗәсенә җитүе – әлеге мәсьәләне хәл итүнең бер юлы. Минем уйлавымча, укучыларны фәнни-тикшеренү эшенә тарту һәм эзләнү нәтиҗәләрен укыту-тәрбия процессында куллану – белем бирүнең иң нәтиҗәле алымнарыннан берсе.
Шуннан чыгып, әлеге авторлык программасы укучылар белән башкарылачак фәнни эшнең максатын, бурычларын, өйрәнү объектын төгәл итеп билегеләргә мөмкин лек бирәчәк. Эзләнү эшләренең этапларын таләпләргә кушканча оештырган очракта, эшнең нәтиҗәсе озак көттермәс.

Мәктәптә татар телен һәм әдәбиятын нәтиҗәле укыту – бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Моның сәбәпләре барыбызга да мәгълүм: татар теле һәм әдәбияты фәннәрен тирәнтен өйрәнү – милләт буларак сакланып калу һәм мәдәниятне үстерүнең иң әһәмиятле юлы. Тел бетә икән – милли мәдәният күргәзмә формада гына яшәп калачак.

Барлык алга киткән илләр экономикасы үсеше күпмедер дәрәҗәдә фәнни идеяләр һәм аларны тормышка ашыру юллары белән бәйләнә. Шуның белән бергә кешенең роле политик, экономик, рухи карашлар системасында үзгәреп тора.

Гомуми белем бирү йортларында да хәзерге тормышка яраклашкан, конкурентлыкка ия булган, грамоталы, иҗади шәхесләр тәрбияләү бурычы килеп басты.

Бу катлаулы мәсьләне чишүдә, әлбәттә, укытучы зур роль уйный. Заман җәмгыятькә яңа идеяләр белән сугарылган, инновацион процесста актив катнашучы, компетент рәвештә фәнни-тикшеренү мәсьәләләрен чишә алучы, укучыларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеген дөрес оештыручы педагог зарури булуын таләп итә.

Хәзерге мәгариф системасында укытучылардан укучыларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеген даими, системалы оештыру сорала.

Фәнни-тикшеренү эшенең четерекле мәсьәләләрен чишү бүгенгесе көндә педагоглар алдына профессиональ бурыч буларак куела.

Әлеге позиция Россия Федерация мәгарифенең милли доктринасында да чагылыш таба. Хәзерге вакытта педагоглар аттестация үткәндә дә, квалификацион категория алганда да таләп ителә.

Бүгенге педагогларның бурычы – укучыларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыру, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен ныгыту, мөстәкыйль рәвештә тикшеренү бурычларын, мәсьәләләрен куярга һәм чишәргә өйрәтү,
сәләтле укучыларны ачыклау, фәнни белемнәрне актуальләштерү һәм тирәнәйтү, танып белү активлыгына, фәнни стильдә фикер йөртү эшчәнлегенә ия булган иҗади шәхес тәрбияләү.

Минемчә, укучыларны фән дөньясына алып керү, кызыксындыру, аларны тикшеренү эшләренә җәлеп итү проблемасы һәр укытучыны уйландыра. Рус мәктәпләрендә эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен бу аеруча мөһим. Ник дигәндә, мондый мәктәпләрдә белем алучы балалар арасында татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынучыларның саны артык күп түгел. Ә укучыларны эзләнү-тикшеренү белән шөгыльләндерә алу бик зур мөмкинлекләр ача, укучыларның сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерергә ярдәм итә. Әдәбият белән кызыксындыруда аеруча нәтиҗәле. Беренчедән, мондый укучылар китапларны күпләп укый башлыйлар, чөнки әдәби әсәр аның эзләнү эшендә төп чыганак булып хезмәт итә. Укучы китап авторының башка әсәрләрен алып укый, чагыштыра, бу темага язылган башка авторларның да хезмәтләрен, әсәрләрен эзли, иҗади фикерли.

Икенчедән, укучының төрле сүзлек, тәнкыйди материаллар белән эшләү күнекмәсе арта. Укучыларда мондый күнекмәләр булдыруга игътибарны көчәйтергә кирәклеге ачык. Торган саен күбәя барган фәнни мәгълүмат эзлекле рәвештә эшли белүне таләп итә.

Эшне башкару барышында кайбер укучыларда киләчәктә фән дөньясын ныклап үзләштерү теләге уяну ихтималын да күз алдыннан югалтырга ярамый. Дәресләребездә утыручы егет һәм кызлар арасында киләсе көн галимнәре дә утырырга мөмкин бит.

“Укымак - фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак - үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак”,- дигән сөекле шагыйребез Габдулла Тукай. Фәнни-эзләнү эшчәнлеге барышында алынган күнекмәләр укучыга башка фән нигезләрен үзләштергә, бердәм дәүләт имтиханнарына, олимпиадаларга әзерләнгәндә зур ярдәм булачак.

Мәктәпләрдә инновацион эшчәнлегенә туры килә торган гадәттәгечә уку-белемне тулыландыру һәм фәнни-тикшеренү юнәләшендәге методик эш нәтиҗәлеләрдән санала. Һәр укытучы үз эшчәнлеген төрле юнәлешләрдә башкара. Шуңа күрә дә гомуми белем бирү йортларында тикшеренү эшчәнлегенә зур игътибар бирелә.

Нәтиҗәлелеккә ирешү өчен мин дә башка укытучылар кебек, үземнең методик эшчәнлегемне түбәндәге юнәлешләрдә алып барам: а) гомуми педагогик әзерлекне тагын да камилләштерү; б) белем бирүнең сыйфатын күтәрү өчен яңа, алдынгы технологияләрне

үз эшемдә актив куллану; в) мәктәп, район, республика күләмендә оештырылган фәнни-тикшеренү эшләрендә укучылар белән актив катнашу һәм тәҗрибә уртаклашу.

Хәзерге җәмгыять өчен укучыларның төрле фәннәрдән тирән белемле булуы гына җитми. Аларның мәктәп программасының база курсын ныклап үзләштергән дигәне дә алган белемен таныш шартларда гына куллана белә, көтелмәгән хәлләр килеп туганда иҗади фикерли, яңа идеяләр белән яши, мөстәкыйль эш итә алмый. Шуңа да әзер белемнәрне үзләштерүдән һәр укучының мөмкинлеген һәм үзенчәлеген күздә тоткан мөстәкыйль танып белү эшчәнлеге дәрәҗәсенә җитүе – әлеге мәсьәләне хәл итүнең бер юлы. Минем уйлавымча, укучыларны фәнни-тикшеренү эшенә тарту һәм эзләнү нәтиҗәләрен укыту-тәрбия процессында куллану – белем бирүнең иң нәтиҗәле алымнарыннан берсе.
Белгәнебезчә, фәнни эшкә әзерлек дәресләрдә башлана. Без, укытучылар, үзебезнең һәр укучыбызның уңышларын һәм уңышсызлыкларын дәрестә ачык күрәбез. Үзлектән эш башкарганда укучының аны теләк белән яки теләксез башкаруын ачык аңлыйбыз. Шуңа күрә фәнни-тикшеренү эшләренә әзерлекне дәресләрдә башларга кирәклеге беркем өчен дә яңалык түгел. Эш алдыннан без укучылар белән берлектә иң беренче актуаль проблеманы формалаштырабыз. Укучыга белем җиткерелми, проблеманы тикшерү барышында алар аны үзләре эзләп табалар. Шуннан чыгып, без укучылар белән башкарылачак фәнни эшнең максатын, бурычларын, өйрәнү объектын билгелибез. Укучылар фәнни эш алымнарын үзләштерә. Эзләнү эшләре түбәндәге этапларда башкарыла.

**Фәнни-тикшеренү эшен башкару этаплары:**

- проблеманы билгеләү яки күзаллау;
- проблеманы кую, аның төгәл яңгырашын билгеләү;
- аңлаешсыз мәсьәләләрне ачыклау (өстәмә әдәбият уку, күзәтүләр үткәрү);
- гипотеза билгеләү;
- планлаштыру;
- фәнни проблеманы хәл итәргә кирәк булган мәгълүматлар туплау;
- җыелган мәгълүматларны системалаштыру, анализлау, синтез;
- тупланган мәгълүматларны проблемага карашларың, фикерләрең белән чагыштыру;
- гипотезаңны исбатлау;
- гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау, йомгаклау;
- Фәнни тикшеренүләр буенча отчет төзү;
- Фәнни тикшеренү нәтиҗәләрен чыгыш яки фәнни текст рәвешенә китереп, башка тикшеренүчеләр игътибарына тәкъдим итү, яклау.

**Фәнни-эзләнү эшенә тема сайлау**

Тема сайлау – фәнни эшнең җитди, җаваплы өлеше, эшнең уңышы шактый дәрәҗәдә тикшеренү объектының дөрес сайлап алуына бәйләнгән. Шуңа күрә фәнни хезмәт өчен теманы укытучы белән укучы бергәләп әзерлиләр. Нинди генә тема алынса да, ул озак һәм киеренке эшләүне, бөтен көч, белем, сәләтеңне бирүне таләп итә.

Фәнни эшнең исеме эшләгән эшне төгәл һәм анык итеп атарга тиеш.

Җирле сөйләм, онамастика темалары күңелгә якын темалар. Татар әдәбиятын рус әдәбияты белән чагыштырмача өйрәнү. Татар телен рус теле, төрки телләр белән чагыштырып карау, халык авыз иҗаты әсәрләрен чагыштырма карау да матур гына нәтиҗәләр бирә, дип уйлыйм мин. Аерым гына бер әсәр өстендә эшләп, аны төрле яктан тикшерү кечерәк яшьтәге балалар өчен уңышлырак булыр. Теманы дөрес сайлау – эшләгән эш уңышының яртысын тәшкил итә.

Алдагы этап – фәнни эшне язу өчен материал туплау. Материалны ничек тупларга соң?

## Фәнни эшне язу өчен материал туплау

Тема ачыклангач, фәнни эш язу материал җыюдан башлана. Иң беренче чиратта темага караган фәнни әдәбиятны барларга кирәк. Татар теле һәм әдәбияты буенча бу әзер библиографик китаплар (мәсәлән, Татар тел белеме библиографиясе (1998), Татар әдәбияты, аерым язучылар турындагы монографияләрдәге библиографияләр һ.б.).

Татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы буенча махсус библиографик белешмәләр юк. “Мәгариф”, “Фән һәм мәктәп”, “Фән һәм тел” журналларында татар теле, әдәбияты һәм аларны укыту мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр даими чыгып тора.Үзегезне кызыксындырган темага караган хезмәтләрне бу журналларның соңгы санындагы шул елда басылган мәкаләләр исемлегеннән табарга була.

Җыелган материалны үзләштерү, теманы яктырту өчен мәгълүмат туплау – тема өстендә эшләүнең иң беренче мөһим этабы. Укучы башта тикшерелә торган **чыганакны** җентекләп өйрәнергә тиеш (әдәбият буенча фәнни эш язганда, ул авторның әсәрләре белән танышу).

Кирәкле мәкалә һәм китапларны эзләп табуда китапханәләрнең **тематик картотекалары** да ярдәм итә. Иң беренче чиратта нинди чыганакларга мөрәҗәгать итәргә кирәклеген фәнни җитәкче күрсәтә.

Кирәкле әдәбиятны дөрес куллануда библиографик картотека төзүнең әһәмияте зур. Тема буенча табылган һәр китапка, журнал яки газета мәкаләсенә аерым карточка төзелә. Моның өчен аерым кәгазь бите (стандарт китапханә карточкасы булса яхшырак) файдалану уңайлы. Аңа авторның фамилиясе, инициаллары, китапның (мәкаләнең) тулы исеме, басылу урыны, елы һәм бите, журнал һәм газета мәкаләләре өчен – газета һәм журналның исеме, номеры, чыккан елы, ае, көне дә күрсәтелә. Әлеге карточкалар фәнни эшнең бүлекләренә ярашлы рәвештә системага салынып, авторлары буенча алфавит тәртибендә урнаштырыла. Болай эшләгәндә, соңыннан хезмәтнең ахырында бирелүче гомуми библиографияне төзү дә җиңел була.

Темага караган фәнни-теоретик әдәбиятны өйрәнүне тарихи-хронологик тәртиптә түгел, ә “кире тәртиптә” алып бару отышлырак. Иң башта соңгы елларда чыккан әдәбият белән танышасың, аннары, эзлекле рәвештә, элеккерәк еллардагы чыганакларны өйрәнәсең. Нәтиҗәдә искергән хезмәтләргә бүгенге көн югарылыгыннан торып бәя бирергә мөмкинлек ачыла, теманың кайсы яклары әле һаман да тиешенчә яктыртылмаганлыгы яки бәхәсле булуы ачыклана.

Фәнни-теоретик әдәбиятны, шулай ук әдәби текстларны һәм тел фактларын өйрәнгәндә язмалар булдыру кирәк. Цитаталар, өзекләр, уку дәверендә үзеңдә туган фикерләрне язу өчен аерым кәгазьләр, карточкалар файдалану мөһим. Һәр биттә яисә карточкада бер генә язма булырга тиеш. Мондый тәртиптә эшләү җыелган материалны төркемләү өчен уңайлы.

Материал туплау, аны системага салу һәм анализлау барышында тикшерүнең төп бурычлары ачыклана, яктыртылырга тиешле проблемалар билгеләнә, шул нигездә эшнең планы төзелә.

План, гадәттә, темага караган әдәбият белән танышканда ук күзаллана. Баштарак ул якынча булып, материал туплау барышында еш кына тулыландырыла, конкретлаштырыла һәм соңыннан фәнни эшнең эчтәлеге итеп куела.

## Фәнни-тикшерену эшенең төзелеше

- **титул бите**;
- **эчтәлек** (бүлек исемнәрен, аларның кайсы биттә урнашуын күрсәтү);

- **кереш** (проблеманың актуальлеге, гипотеза, тикшеренүнең максаты һәм бурычлары);
- **төп өлеш** (тикшеренү алымнары, тупланган мәгълүматлар турында аңлатмалар - җыелган мәгълүматларны системалаштыру, анализ, синтез; тупланган мәгълүматларны проблемага карашларың, фикерләрең белән чагыштыру; гипотезаңны исбатлау);
- **йомгак** (тикшерүнең гомуми нәтиҗәләре, гомумиләштерүләр – гипотезаның дөреслеген яки нигезсез булуын бәян итү);
- **библиография** (кулланылган әдәбият исемлеге);
- **кушымталар** (рәсемнәр, схема, карта, таблица, фоторәсемнәр һ.б.).

## Хезмәтнең язылу тәртибенә таләпләр

Югарыда күрсәтелгән структура - фәнни-тикшеренү эшләренә куелган катгый таләпләрнең берсе.

Эш төзәтүләрсез, хатасыз башкарылырга тиеш.

Хезмәт A4 форматындагы кәгазьгә компьютерда басыла. Кульязма хәлендәге эшләр хәзерге вакытта хупланмый. Конкурс яисә конференция нигезләмәсендә башкача таләп ителмәгән очракта, шрифт - Times New Roman-14, интервал - 1,5, ә полялар 2*2*2*2* үлчәмендә сайлана. Битләр номерлана.

Кушымта эш белән бергә беркетелә. Теркәү өчен пластик файллар, төрле папкалар куллану киңәш ителә. Эшнең күләме аның конкрет максатына һәм үтәлү шартына бәйле.

**Титул бите** – иң мөһим элементларның берсе, һәм ул башлангыч мәгълүматларны үз эченә ала. Анда:

- оешманың тулы исеме;
- фәнни хезмәтнең төре (доклад, реферат, фәнни-тикшеренү эше һ.б.);
- эшнең темасы;
- автор турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме, белем алу урыны, сыйныфы яки төркеме, курсы);
- фәнни җитәкче турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме, эш урыны, вазифасы, гыйльми дәрәҗәсе);
- эшнең башкарылу урыны, датасы күрсәтелә.
- Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.
- Текстта кулланылган әдәбиятка, чыганакларга өстөшермә бирелә.

## Титул битен язу кагыйдәләре:

- Титул бите рамкасыз булырга тиеш.
- Елын язганда "ел" сүзе язылмый.
- Фәнни эшнең исеме битнең уртасына языла, нокта куелмый, куштырнакларга алына.
- Фәнни эшнең исеме мөмкин кадәр кыска һәм эшнең эчтәлегенә туры килергә тиеш.
- Эшнең исеме элегрәк бастырылган фәнни тикшеренүләрне кабатламаска тиеш.

Тезислар:

Ике биттән артмаган, бастырылган һәм түбәндәге мәгълүматтан тора торган текст:

- Эшнең максатыннан чыгып кыскача куелган бурычлар.
- Бурычларның актуальлеге һәм аның кулланылышы (эшкә куелган бурычларның ни өчен сайлануы, аның фәнни-практик әһәмияте).
- Бурычларның методик чишелешен язу (тикшеренүдә нинди методлар кулланылган, нинди эксперимент үткәрелгән).

- Алынган нәтиҗәләрне анализлау: эшне башкаруда алынган төп нәтиҗәләр, аның фәнни-практик кыйммәтен ачыклау, ирешелгән нәтиҗәләрнең моңа кадәр ачыкланганнарыннан нәрсәсе белән яхшырак булуын күрсәтү.
- Файдаланылган әдәбият.

**Фәнни эшнең планын төзү тәртибе:**

I. Кереш өлеш
II. 1 нче бүлек ( теория)
§1, §2 ...
III. 2 нче бүлек (практик эш)
§1, §2 ...
IV. Йомгаклау өлеше
V. Кулланылган әдәбият
VI. Кушымта

**Фәнни эшнең кереш, төп һәм йомгаклау өлешләре.**

Фәнни хезмәт, гадәттә, 3 өлештән тора: кереш, төп өлеш һәм йомгаклау өлешләре.

Кереш өлештә укучы үз хезмәтенең максатын куя, шул максатны тормышка ашыруның бурычларын билгели, теманың фәнни һәм практик яктан актуальлеген, әһәмиятен күрсәтә. Биредә үк мәсьәләнең өйрәнелү тарихы яктыртыла. Әгәр экспериментлар үткәрелгән булса (методика буенча), аларга аңлатма бирелә. Керешнең күләме 3-5 биттән артмаска тиеш.

Кереш өлештә түбәндәгеләр ачыклына:

- теманың актуальлеге;
- эшнең ни дәрәҗәдә өйрәнелүе;
- эшнең максаты һәм бурычлары;
- өйрәнү объекты һәм предметы;
- гипотезалар (гыйбарәләр)
- эзләнү-тикшеренү методлары;
- эшнең (хезмәтнең) фәнни һәм практик яктан бүленеше;
- эшнең структурасы;

Төп өлеш теоретик һәм практик өлешләргә бүленә. Төп өлештә укучы үзе җыйган фактик материалга фәнни анализ ясый һәм һәр бүлек саен тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен күрсәтеп бара. Теоретик өлештә укучы төрле фәнни чыганакларга нигезләнеп өйрәнелгән мәсьәләргә карата үз позициясен белдерә.

Практик өлеш исә аналитик характерда була. Биредә укучы тарафыннан өйрәнелгән тикшеренү мәсьәләренә тирән анализ ясала. Монда ук автор әлеге мәсьәләләргә карата үзенең конкрет тәкъдимнәрен күрсәтә.

Төп өлеш берничә бүлеккә, ә бүлекләр бүлекчәләргә (параграфларга) бүленергә мөмкин. Һәр бүлек 2-3 бүлекчәне үз эченә ала. Бүлекчәләр күләме ягыннан бер-берсеннән нык аерылмаска тиеш. Бүлек һәм бүлекчәләрнең исемнәре төп проблеманың аерым тармаклары рәвәшендә бирелә. Гадәттә, һәр бүлек ахырында кыскача нәтиҗә ясала. һәр бүлек яңа биттән башланып китә. Бүлекчәләр текст буенча дәвам иттереләләр, алдагы бүлекчәдән соң һәм яңа бүлекчә алдыннан юлара интервал гына калдырыла.

Йомгакта укучы тикшеренү барышында алынган теоретик һәм практик нәтиҗәләрне яза, тик ул һәр бүлекнең нәтиҗәләрен санап чыгу гына түгел, ә эшнең гомумиләштерелгән нәтиҗәләре булырга тиеш. Шул ук вакытта аларның кыска һәм төгәл булулары зарури. Димәк, төп өлешне укымыйча да, йомгак аркылы эшнең асылы аңлаешлы булуы шарт. Аның күләме 2-5 бит тирәсе булырга мөмкин.

Йомгак өлеше өйрәнелгән теманың тагы да киңрәк өлкә белән бәйләнешен ачыкларга тиеш, ягъни теманың актуальлеге һәм алга таба өйрәнү перспективасын күз алдында тотып эш итеплә.

Йомгак өлеше өйрәнелгән теманың тагы да киңрәк өлкә белән бәйләнешен ачыкларга тиеш, ягъни теманың актуальлеген һәм алга таба өйрәнү перспективасын күз алдында тотып эш итеплә.

Йомгак түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- фәнни эшнең төп өлеш бүлекләре буенча кыска нәтиҗәләр чыгару;
- кереш өлештә куелган максат һәм бурычларның тулы ачылышы;
- хезмәтнең киләчәктә өйрәнү перспективасы

Йомгакта нәтиҗәләр чыгарудан тыш, тикшерену дәвамында өйрәнелми калган мәсьәләләр һәм эзләнү – тикшеренү барышында барлыкка яңа өйрәнеләсе мәсьәләләр һәм аларны алга таба кайсы юнәлештә өйрәнергә кирәклеге турында әйтеп үтәргә кирәк.

## Файдаланылган әдәбият исемлеге (библиография)

*Файдаланылган әдәбият* исемлеге (библиография) йомгактан соң бирелә. Монда автор эш барышында телгә алган, кулланган фәнни-теоретик китаплар, мәкаләләр алфавит тәртибендә күрсәтелә. Библиографиягә карап, укучы файдаланган материалның күләмен һәм характерын билгеләп була.

Гадәттә, фәнни эшне язганда кимендә 5-10 әдәбият чыганагы кулланыла, аларның исемлеге эшнең ахырында күрсәтелә. Библиография төзүнең берничә ысулы бар. Иң киң таралганы һәм уңайлысы – алфавит тәртибендә төзелгән әдәбият исемлеге, ягъни авторларның фамилиясе алфавит тәртибендә искә алына. Бер үк авторның берничә хезмәте файдаланылган очракта, алар, чыккан елына карап, хронологик тәртиптә урнаштырыла.

Авторлар саны өчтән артса, библиографик тасвирламаны, китап исеменнән башлап, авторларны кыек сызыктан соң күрсәтәләр. Мәсәлән: Татарча-русча сүзлек / И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.А. Юналеева. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1998. – 462 б.

Авторлар саны дүрттән дә артып китсә, кыек сызыктан соң өч кешенең генә фамилиясе һәм инициалы теркәлә, калганнары “һ.б.” дип күрсәтелә.

Фәнни эшнең библиографик мәгълүматлары титул яисә соңгы битендәге кебек түбәндәге схема буенча языла:

Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер, 2002. – 384б..

## Чыганаклар исемлеге

Чыганаклар исемлеген библиографиядән соң урнаштыралар. Чыганакка тикшеренү өчен материал булып хезмәт иткән журналлар, газеталар, сүзлекләр, әсәрләр һ.б. керергә мөмкин. Бу исемлек шулай ук алфавит тәртибендә урнашырга һәм әдәбият исемлеге таләпләренә туры килергә тиеш.

*Аерым том*

Гафури М. Әсәрләр: 4 томда. – Казан: Татарстан кит. нәшр., 1980. – Т.1. -536 б.

*Фәнни җыентык*

Татар теле һәм этносы тарихы мәсьәләләре: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият, сәнгать институты җыентыгы / М.З. Зәкиев мөхәррирлегендә. – Казан, 2000.- 176 б.

*Газетадан алынган мәкалә*

Миңнуллин Т. Татарны саклау – татарның үз бурычы // Мәдәни җомга. – 2002. – 4 окт. – Б.2.

*Журналдан алынган мәкалә*

Вәлиев М. Тәнкыйтьне җанландыру – уртак бурыч // Казан утлары. – 2002. - №8. – Б. 129-131.

*Сайланма әсәрләрдән алынган әсәр*

Камал Г. Безнең шәһәрнең серләре // Сайланма әсәрләр: 3 томда. – Казан: Тат. Китап нәшр., 1978. – Т. 1. – Б. 171-221.

**Кушымта** ***<u>фәнни эшнең азагында, әдәбият исемлегеннән соң, аерым битләрдә бирелә</u>*** . *Кушымта* хезмәткә бик әйбәт өстәмә булып торырга мөмкин. Мәсәлән, анализланган сүзләр исемлеге, ксерокопияләр, фотоиллюстрацияләр, схемалар, транскрипцияләр, фактик материал тупланган карточкалар (аерым конвертта яисә тартмада). Методика буенча башкарылган эшләрдә, гадәттә, дәрес план-конспектлары кушымта итеп бирелә. Кушымталар берничә булса, алар аерым номерлана (1 нче кушымта, 2 нче кушымта...), номер астына кушымтаның исеме языла.

<u>Рәсемнәрне</u> (сызымнар, графиклар, схемалар, диаграммалар) тексттан соң алар беренче тапкыр искәртелгәндә, яисә икенче биттә урнаштыралар.

<u>Таблицалар</u> тексттан соң бирелә. Һәр таблицага сылтама (<u>ссылка)</u> булырга тиеш.

Таблицалар гарәп цифрлары белән тәртип буенча билгеләнә. Номер өске сул якта “Таблица” дигән сүз янына языла.

Әгәр фәнни эштә 1 генә таблица икән, аңа “Таблица” сүзе дә, номер да куелмый.

Һәр таблицаның исеме булырга тиеш. “Таблица” сүзе һәм исеме язма хәрефләрдән башлана. Таблицаның исеменнән соң нокта куелмый.

<u>Сылтамалар (ссылки)</u> таблицаларга, рәсемнәргә, кушымтага түгәрәк җәя эчендә, яисә куштырнаклар эчендә бирелә.

Сылтама бирүнең 2 төре бар:

1. Текст эчендәге сылтамалар (внутритекстовые).
2. Тексттан соң килә торган астөшермәләр (сноска, т.е. подстрочные ссылки)

Компьютер белән эшләгәндә беренче форма уңайлырак.

## Текст эчендәге сылтамалар.

Текст эчендәге сылтамалар файдаланылган әдәбият исемлегендәге номеры шакмак [квадрат] җәяләр эчендә күрсәтелә. Мәсәлән, ... бу турында М.З. Зәкиев [3], Ф.С. Сафиуллина [18] хезмәтләрендә дә әйтелә. Теге яки бу хезмәтнең аерым битләренә искәрмә ясаган очракта, сылтаманы менә болай формалаштыралар:

Ф.С. Сафиуллина болай дип яза “... ... ...” [18,12].

Бу очракта беренче сан – [18] хезмәтнең библиографиядәге номерын, өтердән соңгы сан - [12] искәрмә ясалган битне күрсәтә.

Вариант буларак, мондый язылыш та мөмкин: Ф.С. Сафиуллина [18, 12] болай дип яза: “... ...”.

Күп томлы хезмәтләргә мөрәҗәгать иткәндә, томның номерын да күрсәтәләр: Г. Тукай үзенең “Халык әдәбияты” хезмәтендә түбәндәге фикерләрне язган: “...” [15, т. 4, 261], яисә болай : Г. Тукай [15, т.4, 261] үзенең “Халык әдәбияты” хезмәтендә түбәндәге фикерләрне язган: “... ...”.

## Тексттан соң килә торган астөшермәләр (сноска, подстрочные ссылки).

Тексттан соң килгән астөшермәләрдән хезмәтнең авторын, исемен, басылып чыгу урыны турындагы мәгълүматны я тулысынча, я текстта күрсәтелмәгән өлешен генә китерәләр.

Астөшермәләр текст астында озын сызыктан соң бер интервал аша җыела. Мәсәлән:

Текстта: “Укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап, әсәр өйрәнүнең төрле этапларында методик формалар һәм алымнар да үзенчәлекле”[1.]

Астөшермәдә: 1. Хөснетдинова Л.К. Әдәбият укыту мәсьәләләре. – Яр Чаллы, 2000. – Б.7.

Әгәр фәнни эштә башка телдә язылган хезмәт кулланыла икән, астөшермәдәге мәгълүмат шул телдә язылырга тиеш. Мәсәлән: Текстта: "... ... телнең үз лексикасында кебек, аерым алынмаларның уңай яки тискәре экспрессив – стилистик төсмерләре дә үзгәрде"[1].

Астөшермәдә: 1. Величко А.В. о "русскости" русского языка наших дней // Русская речь. - №6. – с. 54.

Әгәр дә бер үк биттә төрле авторның бер үк җыентыкта чыккан мәкаләләре китерелә икән, икенче астөшермәләрдә әлеге җыентыкның исеме "шунда ук" ка алыштырыла:

I. Астөшермә: Нигъматуллов М.М. Урта һәм югары мәктәптә аналитик фигыльләрне өйрәнү // Актуальные проблемы двуязычия в Республике Татарстан. – Наб. Челны, 1997. – 73-76 б.

II. Астөшермә: Казыйханова З.А. Педагогик вузда студентларны азкомплектлы мәктәптә ана телен укытуга әзерләү // Шунда ук. – 76-78 б.

Һәм соңгы этап - фәнни эшне яклау.

**Фәнни-тикшеренү эшен яклау**

- Үзең белән таныштыру.
- Фәнни-тикшеренү эшенең темасы (ни өчен бу теманы сайлавыңны аңлат).
- Теманың, күтәрелгән проблеманың актуальлеге.
- Фаразлау (гипотезаңны әйт).
- Тикшеренүнең максаты, бурычлар (конкрет, төгәл булсын).
- Тикшеренүдән барлыкка килгән нәтиҗәләр (эш этаплары турында кыскача сөйлә: күзәтүләр, чагыштырулар, анализ, синтез, тупланган мәгълүматларны проблемага карашларың, фикерләрең белән чагыштыр; гипотезаңны исбатла).
- Гомуми йомгак.
- Сорауларга җавап бирү.

Чыгыш өчен 5-7 минут вакыт бирелә.

**Чыгыш ясаганда исеңдә тот! (укучылар өчен)**

- рәислек итүченең рөхсәте буенча гына чыгыш ясa;
- фикереңнең иң кыска һәм мәгълүматка бай вариантын төгәл һәм аңлаешлы итеп әйт (онытма: кыскалыкта – осталык);
- шушы фән өлкәсенә караган терминнарны гына кулланырга тырыш;
- сөйләмеңнең интонациясе, эмоциональ төсмерләре әйтелгән фикерләреңнең эчтәлегенә туры килсен;
- сөйләм телеңдә хаталар булмасын;
- башкалар фикерен кабатламыйча, үз дәлилләреңнең өстен якларын күрсәт;
- озын җөмләләр төземә;
- темадан читкә китмә;
- башкалар тарафыннан яңа фактлар китерелсә, үз фикереңне үзгәртергә әзер тор;
- фикерләреңне нигезлә, дәлилләр китер;
- алып баручының кисәтүләренә һәм тәкъдимнәренә колак сал, башкалар чыгышындагы хаталарны кабатламаска тырыш;
- бирелгән сорауларга җавап бир, җавап таба алмаганда, "...без туплаган мәгълүматларга нигезләнеп кенә әлеге сорауга җавап бирә алмыйбыз, гафу итегез" дияргә оялма;

- тыңлаучыларны хөрмәт итүеңне күрсәт;
- уңайсыз хәлгә калмас өчен, хәбәрдар булмаган мәсьәлә буенча үз карашыңны белдермә;
- нигезләмәләреңдә дөреслеге, фәннилеге тикшерелгән фактларга гына таян;
- ышанычсыз урыннардан мәгълүмат җыйма.

**Чыгышыңда түбәндәге сөйләм формаларын куллан**

- Безнең фикеребезчә, ...
- Безнең күзәтәләр буенча, ...
- Галим Фәләнов Фәлән бу фактны болай аңлата: ...
- Бу проблема түбәндәге авторларның хезмәтләрендә чагыла: ...
- Фәлән чыганактан алынган мәгълүматлар буенча, ...
- Бу мәсьәләне ачыклау өчен, без түбәндәге авторларга мөрәҗәгать иттек: ...
- Тупланган мәгълүматлар түбәндәгеләрне раслый: ...
- Без үткәргән тикшеренүләрдән күренгәнчә, ...
- Сүзне йомгаклап, шуны әйтергә кирәк (шуны әйтү урынлы булыр): ...
- Чыгышымны мондый сүзләр белән тәмамлар идем: ...

Игътибарыгыз өчен рәхмәт...

Фәнгә беренче адымнар ясауга, әлбәттә, мәктәптә үткәрелә торган конференцияләр ярдәм итә. Бу конференцияләрдә укучылар ораторлык осталыгы, үз фикерен дәлилли белү, дискуссия алып бару күнекмәләре ала.

Фәнни эшне яклау вакытында һәр укучы 6-8 минут чыгыш ясый. Чыгыш автореферат рәвешендә алдан әзерләнә. Бу чыгышта ни өчен шушы тема сайлап алынуы, аның актуальлеге, әһәмияте күрсәтелә, төп чыганаклар белән таныштырыла, тикшеренү нәтиҗәләре күрсәтелә. Чыгыш төгәл, конкрет булырга тиеш.

Тикшеренү эшен тәкъдим итүнең классик һәм иҗади моделе бар. Классик модель: теманың актуальлеге һәм яңалыгы, проблеманы чишү юлларына характеристика; эшнең эчтәлеге буенча характеристика язу.

Иҗади модель: стендка документлар, иллюстратив материаллар кую, видеоязма һәм аудиоязмалардан файдалану, презентация, тикшеренүнең төп өлешен оригиналь рәвештә тәкъдим итү, хезмәт буенча нәтиҗә.

Укучы жюри әгъзалары, секциядә катнашкан башка укучыларның сорауларына җавап бирә. Аларга кыска һәм төгәл җаваплар бирелергә тиеш. Һәм секциядә эш тәмамланганннан соң, жюриның ябык утырышында урыннар билгеләнә.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: фәнни эш белән шөгыльләнү укучыны күп нәрсәгә өйрәтә: уйлау мөмкинлекләре киң ачыла, логик фикерләү дәрәҗәсе үсә, төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләргә, төрле чыгышлар ясарга өйрәтә. Ә иң кыйммәте – аларда үз нәтиҗәләрен күргәннән соң иҗат дәрте кабынуы.

**Файдаланылган әдәбият.**

1. Әдәбияттан диплом эшләре. КДУ ның татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары өчен методик кулланма.Төзүче: Х.Миңнегулов.- Казан: КДУ нәшрияты, 1985.-87б.
2. Белых, С. Л. Управление исследовательской активностью ученика: методическое пособие для педагогов средних школ, гимназий, лицеев [Текст] / С. Л. Белых. - М.:Зимородок, 2007. – С.31-46. – (Серия «Методическое обеспечение»).
3. Волкова, Е. В. «Как написать и оформить реферат»: программа элективногоТяглова, Е. В. Методика апробации результатов исследовательской деятельности учащихся [Текст] / Е. В. Тяглова // Исследовательская работа школьников. – 2006. - № 1. – С. 128-138.
4. Диплом эшен ничек язарга? ТөзүчеҮ.Гимадиев.-Уфа ,1984.-39 б.
5. Сәмигуллин Г.Х., Баһавиев И.И. Мәктәптә фәнни тикшеренүләр белән идарә итү. II китап. Яр Чаллы, ИНПО. – 2004.

6. Новиков, А.М. Научно-экспериментальная работа в образовательном учреждении / А.М. Новиков. – М., 1998.

7. Татар теленнән язма эшләрТөзүче: Сәлимов.-Алабуга,1998.-22б.
8.  Фәнни-тикшеренү конференциясе нигезләмәләре.

# Бала тәрбияләүдә Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренең роле

**(Ата-аналар өчен укыту курсы)**

*МБББУ “Сарман гимназиясе” нең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ханова Нурания Вәзир кызы*

**Аңлатма язуы**

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы һәм ата-аналар алдында яшь буынны тәрбияләү бурычлары тора. Кешелеклелек сыйфатларына ия булган, заманы өчен файдалы, рухи һәм физик яктан камил, конкуренциягә сәләтле, белемле шәхес тәрбияләү – безнең төп максатыбыз, чөнки алар – безнең халкыбызның киләчәге. Милләтебезнең язмышы алар кулында булачак. Кече яшьтән үк бала әхлак тәрбиясе алырга, яхшыдан начарны аера белергә, үз иленең һәм халкының ватанпәрвәре булып үсәргә тиеш. Ул матурлыкны күрә белергә, аны сакларга, үзе үк матурлык тудырырга, тормышны, туган телен һәм халкын, илен, әти-әнисен, туганнарын, табигатьне яратырга тиеш.

Замана катлаулы. Әхлак тәрбияләүдә ата-ана, мәктәп һәм укучы үзе катнашырга тиеш. Шушы өчлек бердәй эшләгәндә генә без максатыбызга ирешә алачакбыз. Шулай да балага тәрбия бирүнең төп өлеше ата-аналар җилкәсенә төшә. Ата-аналар да бала тәрбияләүдә татар халкының педагогик мирасына нигезләнергә тиеш. Тәрбия өлкәсендә бик күп хезмәтләр язган, татар милләтенең киләчәген кайгырткан күренекле педагоглар арасында Риза Фәхреддин лаеклы урын тота. Ата-аналарны аның хезмәтләре белән таныштыру бала тәрбияләүдә файдалы булачак.

Бу курс ата-аналар белән тыгыз элемтә булдыру өчен, кызыклы һәм уңай атмосферада балаларның проблемаларын хәл итәргә ярдәм итә. Бала тәрбияләү шактый катлаулы булу сәбәпле, ата-аналарга үз фикерләрен әйтергә, башкалар фикерен тыңларга, анализларга, тәҗрибәләрен баетырга, киңәшләшергә һәм өйрәнергә булыша. Киләчәгебез бәхетле булсын өчен, лаеклы буын тәрбияләү өчен ата-аналарның да белемнәрен күтәрү зыян китерми. Утырышларның эчтәлеге балалар үсешенең психологик, физиологик үзенчәлекләрен, гаилә тәрбиясе типларын, гаиләдә һәм җәмгать урыннарында аралашу, уңай мөнәсәбәтләр булдыру, хис-кичереш, әхлак тәрбияләү, балаларның психик үсешен өйрәнүне күздә тота.

**Курсның максаты:**

- Ата-аналарның бала тәрбияләүдә педагогик карашларын Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренә нигезләнеп баетырга этәргеч бирү;

**Курсның бурычлары:**

- Балаларны өлкәннәр, күренекле шәхесләр, аларның хезмәтләре нигезендә тәрбияләү; үзтәрбиягә өйрәтү.
- Тәрбияле булуның җиңеллеген, ә тәрбияле баланың бик зур хәзинә икәнлеген ата-аналар аша балаларга ирештерү. Баланы нәтиҗә ясарга, дөрес җавап табарга өйрәтергә өйрәтү;
- Күркәм сыйфатлар тәрбияләүнең зарурилыгын, ә ямьсез холыкның зыянын күрсәтү;
- Белем алу, холык тәрбияләү өчен тәртип, тырышлык кебек сыйфатларның әһәмиятен ачыклау.

  Бу программа урта звено укучыларының ата-аналары өчен 6 утырышка исәпләнгән. Курсны 2-3 уку елына бүлеп үткәрергә була.

Ул түбәндәге темалардан тора:

1. Ризаэддин Фәхреддин турында мәгълүмат. Гаилә бәхете – балада ...
2. ”Аның “Тәрбияле ана”, “Тәрбияле ата” хезмәтләре белән таныштыру, аларга күзәтү ясау аша балаларга тәрбия бирергә өйрәтергә өйрәтү”;
3. “Нәсыйхәт” хезмәтенә күзәтү;
4. “Тәрбияле бала” хезмәте аша бала тәрбияләүнең әһәмиятен ассызыклау;
5. “Күркәм холыклар һәм ямьсез холыклар турында Р. Фәхреддин фикерләре ”.
6. “Шәкертлек әдәпләре” турында берничә сүз.

Программаның актуальлеге ата-аналарда бала тәрбиясе буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат һәм бурычлардан чыгып билгеләнә.

**Программаның эчтәлеге**

**I утырыш** (1 сәгать) **Ризаэддин Фәхреддин турында мәгълүмат.**

**Гаилә бәхете – балада ...**

Мәшһүр педагогның тормыш юлы, иҗаты, педагогик карашлары, вазифалары, аерым хезмәтләре белән кыскача таныштыру аша татар халкының киләчәге өчен бик тә әһәмиятле кыйммәтләр булдыру. Гыйлем өйрәтү, укыту белән генә чикләнмичә, тәрбия бирүнең әһәмиятен аңлату. Галимебезнең үзенең дә белем, тырышлык, тәрбиялелек ягыннан күпләргә үрнәк булуын төшендерү.Балаларның сәламәтлеге, материаль ягы белән беррәттән аның күңел тынычлыгы турында да кайгырту. Коръән сурәләреннән, хәдисләрдән утырыш темасына карату мисаллар карау. Анкета.

**II утырыш. ”Аның “Тәрбияле ана”, “Тәрбияле ата” хезмәтләре белән таныштыру, аларга күзәтү ясау аша балаларга тәрбия бирергә өйрәтергә өйрәтү”**

Бала шәхесенең алга таба үсешен тәэмин итеп, танып-белүгә, тирә-юньне аңларга омтылыш хисен үстерү. Аналарның ике төргә бүленеше, аналарга йөкләнгән вазифаның әһәмиятен аңлау, гаиләдә ата һәм аналар арасындагы мөнәсәбәтләрнең нинди булырга тиешлегенә басым ясау.Баланың үз-үзенә ышаныч мотивациясе булдыру һәм аны сүндермәүдә ата- аналарның үзара мөнәсәбәтенең әһәмиятен өйрәнү. Педагогик ситуацияләр чишү. Баланың үз-үзенә ышаныч булдырырга ярдәм итү өчен эмоциональ һәм физик тотрыклылыкны булдырырга ярдәм итә торган факторларны өйрәнү. Бала фикеренә түземле мөнәсәбәт булдырырга өйрәнү. Сорауларга җавап.

**III утырыш. “Нәсыйхәт” хезмәтенә күзәтү** (1 сәгать)

“Нәсыйхәт” китабы ата-бабаларыбызның гаҗәеп бай акыл хәзинәсенә нигезләнгән һәм мең еллар буена тупланып килгән милли гореф-гадәтләребезнең , йолаларыбызның, гаилә кануннарыбызның, әхлак, әдәп, тәртип, сәламәтлек, ислам диненең һәм дә халык педагогикасын берләштергән бер чыганак булуын ассызыклау. Җәмгыятебездә шәхес тәрбияләү, милләтебезне саклау өчен бик зарури булуын аңлату. Балаларыбызга әхлак тәрбиясе бирүдә кирәкле кулланма икәнен төшендерү. Педагогик ситуацияләр чишү. Сорауларга җавап.

**IV утырыш. “Тәрбияле бала” хезмәте аша бала тәрбияләүнең әһәмиятен ассызыклау (1 сәгать)**

Тәрбияле баланың хәзинә булуын, тәрбияле булуның җиңеллеген аңлау һәм аңлату.Баланың сәләтен аңлы һәм максатчан үстерергә өйрәнү. Актив эшчәнлеккә һәм аны анализларга этәрүче хәл-вакыйгаларны кабатлап тору уңай нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм

итүен күрсәтү. Башкаларның характерын анализлаганда , үзеңнең дә тискәре якларыңны күрә һәм дөрес нәтиҗә ясый белү:

- Ир бала тәрбиясеннән кыз балаларныкының аерылуы;
- Үз ялгышларыңа һәм кимчелекләреңә тәнкыйди карау;
- Күркәм гадәтле булу, тәрбиянең һәр җирдә күренүе;
- Ялкаулыкка каршы көрәшергә;

Педагогик ситуацияләр чишү.

**V утырыш. "Күркәм холыклар һәм ямьсез холыклар турында Р. Фәхреддин фикерләре" (**1 сәгать**)**

Күркәм холыкның күрсәткече буларак тугрылык, тырышлык, мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек, юмартлык, әдәп, сабырлык, шөкер итү, олыларга хөрмәт, кечкенләрне ярату, гаделлек, әманәт, схздә тора белү, тәүбә турында кыскача аңлату һәм ямьсез холыклар турында сөйләшү. Ялган һәм хәйлә, гайбәт сөйләү, урлашу, кеше үтерү, аракы эчү, отышлы уеннар уйнау, зина, яла ягу, тәкәбберлек, исраф, көнчелек, гөнаһ кебек сыйфатларның кешеләрне артка илтүе, милләтебез өчен куркыныч булуы фикерләрен Р. Фәхреддин хезмәтләрендә бирелешен аңлату. Педагогик ситуацияләр чишү. Сорауларга җавап бирү.

**VI утырыш. "Шәкертлек әдәпләре" турында берничә сүз (1 сәгать).**

Фән һәм белемнең әһәмияте, дәрес вакытында үз=үзеңне тоту кагыйдәләренең бирелеше. Укытучыга мөнәсәбәт, дуслар сайлау, буш вакытны ничек үткәрү буенча мөгаллим киңәшләре, тырышлыкка, китап укырга , тәртипле булырга чакыру. "Адәм баласы үзен үзе тәрбияләргә, камилләшергш тиеш, буй җиткән һәр кеше үзен тәрбияли ала", - дигән фикерен ата-аналарга һәм алар аша балаларга җиткерү. Сорауларга җавап бирү

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 нче утырыш | Ризаэддин Фәхреддин турында мәгълүмат. Гаилә бәхете – балада... | 1 |
| 2 нче утырыш | Р. фәхреддиннең "Тәрбияле ана", "Тәрбияле ата" хезмәтләре белән таныштыру, аларга күзәтү ясау аша балаларга тәрбия бирергә өйрәтергә өйрәтү"; | 1 |
| 3 нче утырыш | "Нәсыйхәт" хезмәтенә күзәтү | 1 |
| 4 нче утырыш | "Тәрбияле бала" хезмәте аша бала тәрбияләүнең әһәмиятен ассызыклау | 1 |
| 5 нче утырыш | Күркәм холыклар һәм ямьсез холыклар турында Р. Фәхреддин фикерләре . | 1 |
| 6 нчы утырыш | "Шәкертлек әдәпләре" турында берничә сүз. | 1 |

***Программаны тормышка ашыру юллары***

Программаның эчтәлеге ата-аналарда бала тәрбиясе буенча белемнәр формалаштыруда Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренең әһәмияте куелган максат һәм бурычлардан чыгып билгеләнә. Программаны тормышка ашыру юллары һәм методлары төрле: мониторинг, семинар, очрашу, лекция, анкетелар, педагогик ситуацияләр чишү һ. б. ларны үткәрү ата-аналарның әзерлек дәрәҗәсеннән тора. Аеруча аларга лекцияләр тыңлау, педагогик ситуацияләр чишү кызыклы. Ата-ананың тйп бурычы баласына яхшы тәрбия бирү, шунлыктан

аларда кызыксыну артсын өчен эш формалары чиратлаштырыла. Ата-ана үз белемен дә күтәрергә, бала тәрбиясенә кагылышлы материаллар белшн танышырга, бирелгшн сорауларга үзлектән җавап табарга тиеш. Әмма нәтиҗәләрне укытучы белән берлектә ясау отышлырак. Бу укытучыдан да зур әзерлек, белемен даими камилләштереп торуны сорый. Шулай ук тәрбия мәсьәләсенә кагылган чыганаклар белән алдан танышып, тикшерү эшен дә алып барырга тиеш. Гаилә тәрбиясе буенча утырышларны да ул оештырырга тиеш.

Курсның темалары актуаль, Риза Фәхреддин хезмәтләренә нигезләнеп, ата-аналар аша балага йогынты ясап була. Чөнки алар бала өчен иң кадерле, иң кирәкле, абруйлы, хөрмәткә лаеклы кешеләр.

***Көтелгән нәтиҗәләр***

Бу укыту курсын үткән ата-аналар:

- Үз гаиләсенә, балаларына , башкаларга хөрмәт белән карый;
- Үзтәрбиянең өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә зарурилыгын аңлый;
- Тормышта төрле ситуацияләрдән чыгу юллары белә;
- Баласы өчен үрнәк булырга омтыла, татар халкының күренекле галимнәренең хезмәтләренә нигезләнә;
- Үз өстендә даими эшли, тәрбия мәсьәләләре белән кызыксына; үз язмышына, баласына битараф булмый; горурлык хисләре кичерә.

Бу авторлык программасы ата-аналарга бала тәрбияләү мәсьәләләрен тирәнрәк аңларга, өйршнергә мөмкинлек бирә. Программа буенча эшчәнлек нәтиҗәләре балаларның үз-үзенә ышанычын арттыра, холкын камиләштерә, тормышта үз урынын табарга ярдәм итә.

***Кулланылган әдәбият***


1. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: “Дом печати” нәшрияты. – 2001.
2. Фәхреддинев Р. Р. Нәсыйхәт. Әхлак гыйлеменнән/ Ризаэддин Фәхреддин. – Казан : Мәгариф, 2005. – 184 б.

3.Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагогтРизаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. IV кисәк. – Казан, 20087. – 212 б.

4. Бондаревская Е.В. Мәгарифне модернизацияләү шартларында шәхескә якын килү технологиясен куллану. Методист. Фәнни-методик журнал. М., 2003. №2

5. Мәктәптә бала тәрбиясе. Яңа алымнар һәм технологияләр/ Под ред. Н. Е. Щурковой. – М., 1992 г.

6. Журналы: «Мәгариф», “Фән һәм мәктәп”, «Классный руководитель», «Справочник классного руководителя», «Классный руководитель».

7. Интернет ресурслар.

## 9 НЧЫ КЛАССТА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЕ ӨЧЕН

## ”ЯЗУЧЫЛАР – САРМАН ТӨБӘГЕННӘН” ЭЛЕКТИВ КУРС ПРОГРАММАСЫ

*МБББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле, әдәбияты укытучысы Арсланова Гөлия Мөхәммәтлатыйп кызы*

### Аңлатма язуы

Заман алып килгән яңалыклар, үзгәрешләр уку-укыту эшчәнлегенә дә үтеп керде. Хәзерге чорда фәннәрне укыту эчтәлеген регионлаштыру, ягъни әйләнә тирәбездәге чынбарлыкка бәйләү, тәрбия процессын яңартуның бер юнәлеше булып тора. Педагогик әдәбиятта ул милли-региональ компонент термины белән йөртелә. Милли төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый-географик мохитен, традицияләрен чагылдырган укыту материалын берләштерә. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законнары, аларның үтәлүен тәэмин итү программалары укыту-тәрбия процессына милли-региональ компонент кертүнең хокукый нигезе булып тора.

Укучы үзе яшәгән төбәкне яратсын, аның мәдәни, тарихи кыйммәтләре турында уйлап фикер әйтә алсын өчен, укыту процессында моңа өйрәтергә кирәк. Укытучыларның бүгенге көндә иң зур бурычы - күренекле якташларның эшчәнлеген укучылар күңеленә җиткерү, кызыксындыру, өйрәнү омтылышын тәрбияләү, талантлы якташлары белән горурлык, ватанпәрвәрлек хисен үстерү, камилләштерү.

Бүгенге көндә Сарман якларыннан дистәләгән язучы, шагыйрь, драматург, публицист үсеп чыкты. Бу кадәр язучыны әлегә Арчадан кала республикабызның бер генә төбәге дә бирә алганы юк. Алар белән белән без хаклы рәвештә горурланабыз.

Югарыда әйтелгәннәр электив курсның **актуаль** булуын күрсәтә.

**”Язучылар – Сарман төбәгеннән” электив курсы түбәндәге максатларны куя:**

1.Сарман төбәгеннән чыккан язучылар тормышы, иҗаты турында тирәнрәк мәгълүмат бирү.

2.Районыбыз тарихына бәйле шәхесләрне, мәгариф һәм сәнгать тарихын эзлекле өйрәнү.

3.Укучыларның гуманитар фәннәрдән белемнәрен тирәнәйтергә булышу.

4.Укучыларда туган җиргә мәхәббәт, туган төбәккә бәйле күренекле кешеләргә хөрмәт һәм горурлану хисләре тәрбияләү.

**Төп бурычлар:**

1.Балаларның иҗат активлыгын көчәйтергә этәргеч бирү- милли үзаң тәрбияләү.

2.Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.

3.Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.

4.Укучыларның дәрестә алган белемнәрен системага салу, тирәнәйтү, үстерү һәм ныгыту, эзләнү күнекмәләре булдыру.

5.Якташ язучылар иҗатының гомумтатар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгеләү.

**Көтелгән белем нәтиҗәләре:**

1.Якташларыбыз турында мәгълүматлы булу.

2.Әңгәмә-дискуссияләрдә катнашу, үз фикереңне әйтү.

3.Укучыларда милли үзаң формалаштыру, туган төбәктә намуслы хезмәт итү теләге уяту.

4.Үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, үстерү һәм саклау өчен, үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү.

**Билгеләнеше:**

”Язучылар – Сарман төбәгеннән”электив курсы белем биреп кенә калмый, ә мөстәкыйль эшчәнлек күнекмәләрен булдырырга һәм һәр баланың шәхси мөмкинлекләрен ачарга, өлкән сыйныфларда укыячак профильне сайларга ярдәм итә.

**Электив курсның эчтәлеге**

1. Сарман төбәге язучылары турында гомуми мәгълүмат белән таныштырырга, аларның иҗаты турында гомумиләштерелгән фикер әйтергә өйрәтергә.
2. Сарман районы Чукмарлы авылында туган язучы, драматург, Татарстан Республикасының халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, М.Горький исемендәге премия лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Аяз Мирсәет улы Гыйләҗевнең тормыш юлы һәм киңкырлы иҗаты белән тирәнтен танышу.
3. Аяз Гыйләҗев. “Яра”, “Җомга көн кич белән” повестьларында катлаулы язмышка ия геройларны ң бирелеше, аларның рухи дөньялары бүгенге тормыш чынбарлыгының иң мөһим мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнүе.
4. Сарман районы Иске Теләнче авылында туган Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрә Гөлшат Зәйнашева - татар җыр поэзиясендәге зур хезмәтләре өчен Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе белән бүләкләнгән бердәнбер хатын-кыз шагыйрә. Туган җиргә мәхәббәт, Ватанга бирелгәнлек, халкыбыз язмышы турында кайгырту, намуслы хезмәткә өндәү, кешелек дөньясы кабул иткән югары әхлакка чакыру — аның җырларының төп сыйфатлары. Драматургия өлкәсендәге эшчәнлеге.
5. Сарман районы Янурыс авылында туган язучы, тәрҗемәче Зарипов Марсель Харис улының тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге. "Поступь моей республики" һәм "Выгодный оборот" дигән очерклары һәм публицистик китаплары өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнүе. Журналистика өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе белән бүләкләнүе. Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре.
6. Аяз Гыйләҗев “Йәгез, бер дога” романы. Гариф Ахунов әйткәнчә: “Роман ансат укылмый торган әсәрләр рәтенә керә” .
7. Сарман районы Нөркәй авылында туган Сөббух Рәфыйковның тормышы, иҗаты. Репрессияләнгән шәхес язмышы. С. Рәфыйковның, язучы буларак, киң җәмәгатьчелеккә «Беренче яз» романы белән танылуы. «Үсү җырлары», «Соңгы талпыну», «Үсмерчак» җыентыклары, «Ак төннәр» шигъри китабы турында мәгълүмат бирү .
8. Дамир Гарифуллинның "Нурильдаг тоткыны" китабында язучы Сөббух Рафиковның репрессиядә үткән чорын яза.
9. Сарман районы Рангазар авылында туган Рәфкать Кәраминең тормышы, иҗаты. Прозасында кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, рухи һәм әхлакый каршылыкларны яшәүнең мәгънәсе, матди байлык, мәхәббәт, гаилә, бәхет кебек

фәлсәфи категорияләр яктылыгында тасвирлавы. «Сагышлы кояш», «Ындыр тулы кибән», «Мәхәббәт бураннары», «Йөрәгемне ут алган» повестьлары.

10. “Каргышлы этаплар” романы язучының авылдашы - 58нче маддә буенча хөкем ителгән Сарман районы Рангазар авылы кешесе Мөдәрисов Нурмөхәммәт Мөдәрис улы тормышыннан алып язылган. Әсәр әүвәл «Казан утлары» журналында, аннары, аерым китап булып, Татарстан китап нәшриятында басылып чыга. 1998нче елда роман буенча Татарстан радиосында радиопостановка эшләнә һәм кат-кат радиодан тапшырыла. «Каргышлы этаплар» романы өчен автор 1999нчы елда Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләгенә лаек була.
11. Сарман районы Яхшы Каран авылында туган Мифтах Вәдүтнең тормышы, иҗаты. Бөек Ватан сугышы башлануга фронтка киткән, Мәскәү тирәсендәге авыр сугышларда катнашып, зур батырлыклар күрсәткән һәм гади солдаттан полк комсоргы-политругы дәрәҗәсенә күтәрелгән, шунда КПСС членлыгына кандидат итеп алынган, шигъри таланты әле ачылып та өлгермәгән фронтовик шагыйрь.
12. Сарман районы Чукмарлы авылында туган, унынчы классны тәмамларга да өлгерми, фронтка китеп, Ерак Көнчыгышта япон самурайларына каршы көрәштә катнашып яраланган, озак вакытлар дәваланганнан соң, 1947 нче елда туган авылына кайткан Әзһәр Габидинең тормышы, иҗаты. Шигырьләрендә туган як, андагы кызыклы вакыйгалар сурәтләнеше.
    Әзһәр Габиди - Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия иясе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Әзһәр Габиди – 6 китап авторы. "Без – яз дуслары”, "Тапкырҗан табышмаклары”, "Без бергә”.
13. Сарман авылы егете язучы һәм журналист Хәниф Хәйруллин. Беренче публицистик әсәрләре. “Бакыр базының серләре”, “Алмаз ихтыяр”, “Канлы еллар, авыр еллар”, “Хуҗида үскән батыр” дигән документаль характердагы повесть-очерклары. “Канатлар талмасын”, “Картлык... кемгә шатлык”, “Фатыйманың бәхете” повестьларына күзәтү.
14. Утыз елга якын гомерен балалар укытуга, аларда туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләүгә багышлаган Әзһәр Габиди - Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия иясе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. "Өч киңәшче”, "Кошчыгым”, "Таң сәгате” исемле җыентыклары. Шигырьләрендә табигать һәм кеше бер бөтен булып чагылуы.
15. Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган Клара Булатова – лирик җанлы, романтик рухлы, фәлсәфи карашлы, гражданин хисле әдибә. Ул – бөтен җаны-тәне белән авыл шагыйрәсе, яшьлек, мәхәббәт җырчысы. Аның шигърияте – хыялның һәм илһамның мәңге саекмас, мәңге кимемәс чишмәсе булган табигатьтән, "өянкеләр елап, таллар җырлап төшкә кергән” туган җирдән, ата-бабаларыбыз үткән, замандашларыбыз нык басып барган юлдан.
16. Сарман районы Чураш авылында туган Вәсимә Хәйруллина - шагыйрә-мөгаллимә. Шигърияткә мәктәп аша, балалар күңеле аша килгән, шигырьләрен үз дәресләрендә мәктәп программасына өстәмә материал сыйфатында балалар тәрбияләүдә файдаланган... Шигырьләре дөньяны танып белү буенча да, тәрбия ягыннан да әһәмиятлеләр.
17. Сарман районы Иске Минзәләбаш авылында туган язучы, тәрҗемәче, СССР Язучылар берлеге әгъзасы Адлер Тимергалин — татар совет әдәбиятында фәнни-фантастик жанрны үстерүгә күп көч салган һәм хәзергәчә бу жанрда нәтиҗәле эшләп килгән «саф фантаст» язучы. Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем иясе. Туган авылындагы җидееллык мәктәптә физика һәм математика фәннәре укытучысы. Казанда Пионерлар йортында фәнни-техник түгәрәк җитәкчесе. А.Тимергалин «Сердце Змеи» повестен, башка рус фантаст-язучыларының аерым хикәяләрен һәм А. П. Романовның «Конструктор космических кораблей» документаль әсәрен татарчага тәрҗемә итүче. Мәктәпләр өчен физика дәреслекләре тәрҗемә итеп килә.

18. Сарман районы Ләке авылында туган Ямаш Игәнәй (Ананий Нестер улы Малов) – керәшен халкының “асыл заты”. Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач, туган районының Рантамак һәм Азалак авылы мәктәпләрендә балалар укытуы. Яшь татар поэзиясендә үзенең тормыш, яшәү турында, кичергәннәре турында фәлсәфи уйланулар рәвешендә язган кыска шигырьләре белән билгеле булуы. «Йолдыз булып ян», «Хәзинәләр иле» китаплары.
19. Сарман районы Күтәмәле авылы кызы Диләрә Зөбәерова - Татарстан АССРның атказанган культура работнигы. Татарстанның төрле төбәкләрендә укытучы, район мәгариф бүлеге инспекторы, район газеталарында тәрҗемәче, әдәби хезмәткәр. «Дустым авазы» , «Куш өянке шаһит», «Кыр чәчәге» повестьларында бүгенге яшьләр тормышын, аларның хыялларын, мәхәббәтләрен, тормыштагы каршылыкларны җиңә-җиңә алга таба баруын лирик, романтик буяулар белән тасвирлавы.
20. Сарман районы Мортыш Тамак авылында туган Мәдинә - Маликова укучыларның ихтирамын казанган автор. Хикәяче, романчы, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе. Хикәя-повестьларында яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр, гаилә һәм тәрбия проблемалары, кешенең җәмгыятьтәге урыны, бурычы, хезмәткә карашы мәсьәләләре чагылыш табуы.
21. Сарман районы Зур Нөркәй авылы кызы Саимә Ибраһимова - танылган журналист, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче. Татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итүче. Журналистика өлкәсендәге хезмәтләре өчен С. Ибраһимова 1974 елда Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемгә лаек булды.
    С. Ибраһимова — СССР Язучылар союзы члены.
22. Сарман районы Каташ-Каран авылы егете шагыйрь, прозаик, публицистик Нияз Акмал. «Сарман җыры» поэмасы. Публицистикадагы эшчәнлеге. "Учак” исемле беренче җыентыгы, "Үз урамым” исемле повестьлар җыентыгы.
23. Сарман районы Яхшыбай авылында туган, гаҗәеп талантлы, "китап җене" кагылган, "җитмеш төрле һөнәргә" ия кеше Дамир Гарифуллин - Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Россиянең гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, Сөббух Рәфыйков премиясе лауреаты, Саҗидә Сөләйманова премиясе лауреаты, Сарман энциклопедиясен язган, исеме Татар энциклопедиясенә кертелгән әдип.
24. Озын, бай, катлаулы хезмәт юлын Дамир Хәйруллович вөҗдан пакьлеге, намуслы эш-гамәлләре белән үткән. Аның бөтен эшчәнлеге халыкны белемле, әхлаклы, мәдәниятле итү рухы белән сугарылган. Район тормышында тирән эз калдырган, аның йөзен билгеләүче атаклы кешеләренә багышланган "Сарман районы энциклопедиясе" Сарманның мәңге җуелмас елъязмасы булырлык итеп иҗат итүче.
25. Сарман районы Дүсем авылы егете Фәрит Зәкиҗан улы Яхин - шагыйрь, язучы-прозаик, әдәбият галиме. Беренчеләрдән булып дини мәсьәләләрне яктырткан әдәби һәм фәнни хезмәтләре: «Пәйгамбәрләр тарихы» , «Иман» китаплары, «Пәйгамбәребез Мөхәммәд» трилогиясе. Ф.Яхинның турыдан-туры катнашы белән әзерләнгән Әхмәд Ясәви хикмәтләре, Сәйядинең «Дастаны Бабахан»ы, Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин»е , Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» кыйссасы, «Бакырган китабы» .
26. Сарман районы Каташ Каран авылында туган Нәсим Акмал. Гайбәт итеп түгел, гыйбрәт итеп: "Өч көнлек килен” хикәясе.
27. Сарман районы Урта Кәшер авылында туып үскән Рафис Гыйззәтуллин - җәлилче Зиннәт Хәсәновның туганы. Тормыш юлы, иҗаты. Хикәяләре. Рафис Гыйззәтуллинның хикәяләре кеше күңеленең эчке дөньясын ачып бирүгә нигезләнгән. Ул иҗат иткән хикәяләр аның «Очучы буласым килә», «Урман юлы», «Көтелмәгән сорау», «Кырау», «Багалмада кунакта», «Төнге яңгыр» исемле китапларына тупланган.

28. Сарман районы Нөркәй авлында туган Нәфкать Мостафинның лирик герое - якты күңелле, саф татарча фикерләүче, моңлана, уйлана белүче зат.
29. Сабый җанлы шагыйрь Дамир Гарифуллин. "Ишегалды", "Кикринур", "Бакакак", "Тылсымлы шакмаклар" җыентыклары.
30. Әзһәр Габиди "Без – яз дуслары”, "Тапкырҗан табышмаклары” җыентыклары.
31. Вәсимә Хәйруллина "Чәчәкле төш", "Көмеш балдак", "Тормыш бакчасы", "Чәчәк саен бер кояш", "Син бик кирәкле кеше", "Табышмаклы букча” җыентыклары.
32. Авылдаш шагыйребез Дамир Гарифуллин белән очрашу
33. Сарман төбәге язучылары турында чыгышлар әзерләп, презентацияләр яклау
34. Йомгаклау. Зачет-дәрес.

**Тематик план**

| № | Тема | Сәг | Үткәрү формасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Сарман төбәге язучылары турында мәгълүмат | 1 | Әңгәмә, лекция |
| | **Габдулла Тукай премиясе лауреатлары** | | |
| 2 | Язучы, драматург Аяз Гыйләҗев. Тормышы, иҗаты. | 1 | әңгәмә, лекция |
| 3 | Аяз Гыйләҗев. “Яра”, “Җомга көн кич белән”повестьлары | 1 | Сәяхәт-дәрес |
| 4 | Гөлшат Зәйнашева - җырчы-шагыйрә. | 1 | Шигырьләрен уку, фикер алышу |
| 5 | Язучы, тәрҗемәче Зарипов Марсель Харис улының тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге | 1 | Әңгәмә, лекция |
| | **Репрессияләнгән шәхесләребез** | | |
| 6 | Аяз Гыйләҗев **“**Йәгез, бер дога” романы | 1 | Эзләнү-тикшеренү эше |
| 7 | Сөббух Рәфыйковның тормышы, иҗаты. | 1 | Әңгәмә, лекция |
| 8 | Дамир Гарифуллин "Нурильдаг тоткыны" (язучы Соббух Рафиков турында) | 1 | Китап тәкъдир итү |
| 9-10 | Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты язучы Рәфкать Кәрами. Тормышы, иҗаты. “Каргышлы этаплар” романы | 2 | Әсәрләре буенча фикер алышу |
| | **Фронтовик шагыйрьләребез** | | |
| 11 | Мифтах Вәдүт. Тормышы, иҗаты | 1 | Әңгәмә, лекция |
| 12 | Әзһәр Габиди - Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия иясе. | 1 | Иҗади эш “Туган ягымның киләчәге” |
| 13 | Язучы һәм журналист Хәниф Хәйруллин. | | |
| | **Мөгаллим шагыйрь-шагыйрәләр** | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 | Әзһәр Габиди. "Без бергә", "Өч киңәшче", "Кошчыгым", "Таң сәгате" исемле җыентыклары. | 1 | Шигырьләрен уку, фикер алышу |
| 15 | Клара Булатова - авыл шагыйрәсе, яшьлек, мәхәббәт җырчысы. | 1 | Әңгәмә, күзәтү |
| 16 | Вәсимә Хәйруллина - шагыйрә-мөгаллимә | 1 | Әңгәмә, сәнгатьле уку, |
| 17 | Адлер Тимергалин — «саф фантаст» язучы | 1 | Эзләнү-тикшеренү эше |
| 18 | Ямаш Игәнәй (Ананий Нестер улы Малов) – керәшен халкының "асыл заты". | 1 | Әңгәмә, күзәтү |
| 19 | Диләрә Зөбәерова - Татарстан АССРның атказанган культура работнигы | 1 | |
| **Язучы, публицист, тәрҗемәче, галим** | | | |
| 20 | Мәдинә Маликова - укучыларның ихтирамын казанган автор. | 1 | Эзләнү-тикшеренү эше |
| 21 | Танылган журналист, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче Саимә Ибраһимова | 1 | Әңгәмә, күзәтү |
| 22 | Шагыйрь һәм прозаик Нияз Акмал. «Сарман җыры» поэмасы | 1 | Лекция,сәнгатьле уку,әңгәмә |
| 23-24 | Дамир Гарифуллин - «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре», СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Россиянең гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, Сөббух Рәфыйков премиясе лауреаты, Саҗидә Сөләйманова премиясе лауреаты, Сарман энциклопедиясен язган, исеме Татар энциклопедиясенә кертелгән әдип | 2 | Лекция, сәнгатьле уку, әңгәмә |
| 25 | Шагыйрь, язучы-прозаик, әдәбият галиме Фәрит Зәкиҗан улы Яхин | 1 | Лекция, күзәтү әңгәмә |
| 26 | Нәсим Акмал. Гайбәт итеп түгел, гыйбрәт итеп: "Өч көнлек килен" хикәясе | 1 | Лекция, күзәтү, әңгәмә |
| 27 | Рафис Гыйззәтуллин - җәлилче Зиннәт Хәсәновның туганы. Тормыш юлы , иҗаты. Хикәяләре. | 1 | Лекция, әңгәмә |
| 28 | Нәфкать Мостафинның лирик герое - якты күңелле, саф татарча фикерләүче, моңлана, уйлана белүче зат. | | |
| **Балалар әдәбияты** | | | |
| 29 | Сабый җанлы шагыйрь Дамир Гарифуллин. "Ишегалды", "Кикринур", "Бакакак", "Тылсымлы шакмаклар" җыентыклары | 1 | Лекция, сәнгатьле уку, әңгәмә |
| 30 | Әзһәр Габиди "Без – яз дуслары", "Тапкырҗан табышмаклары" җыентыклары | 1 | Эзләнү- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тикшеренү эше |
| 31 | Вәсимә Хәйруллина "Чәчәкле төш", "Көмеш балдак", "Тормыш бакчасы", "Чәчәк саен бер кояш", "Син бик кирәкле кеше", "Табышмаклы букча" җыентыклары. | 1 | Лекция, сәнгатьле уку, әңгәмә |
| **Еллык эшкә нәтиҗә** | | | |
| 32 | Авылдаш шагыйребез Дамир Гарифуллин белән очрашу | 1 | |
| 33 | Презентацияләр яклау | 1 | Редакциягә сәяхәт |
| 34 | Йомгаклау.Зачет-дәрес | 1 | |

## Кулланылган әдәбият


1. Акмалов Н. "Үз урамым", Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1988.
2. Ахунов Г. "И кадерле туган як", Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1971.
3. Айбулат Р." Берүзе биш кешене алыштыра ", Мәгърифәт,1998, №5.
4. Бәйрәмова Г. "Яхшы атлар үргә чабып менә", Идел, 2001, № 6.
5. Белоусова Л. "Нәселебезнең асыл заты", Мәйдан" № 4, 1997.
6. Вәли-Барҗылы М. "Күңелем кошы", Казан: "Мәгариф", 2004.
7. Габиди А. "Биеклекләр әйдәп торсын!", Татарстан яшьләре,1981, №11.
8. Гәрәев Р. "Исеме яши, эше яши", Социалистик Татарстан, 1983, 15нче июль.
9. Гыйләҗев А. "Бала чагым — бал чагым", Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1997.
10. Гыйльманов Г. "Моң елгасы", Казан утлары, 1988,№ 5.
11. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. "Совет Татарстаны язучылары" , Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1986.
12. Даутов Р.Н., Рахмани Р.Н. "Әдипләребез", библиографик белешмәлек, 1 том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009.
13. Закир М. "Йомшак агачны корт баса", Казан утлары, 2002, № 1.
14. Исмәгыйлов Т. "Сарман" китабы, Казан: Абак, 1998.
15. Камалов Б. "Сагындыра әдип", Социалистик Татарстан, 1973, 15нче июль.
16. Могыйнов Р. "Язучы, журналист, тарихчы", "Мәйдан" журналы, 2002, декабрь.
17. Мостафин Р "Әдәбиятыбызның имән баганасы", Мәйдан" журналы, 2000, март.
18. Мулланурова Р." Тәгәрәйләр китте йөрәгем...", Сөембикә, 1996, № 4.
19. Низамиев М. "Сарман тарихчысы", Ватаным Татарстан, 2009, 31нче октябрь.
20. Сверигин Р. "Мотаһирның каргышлы язмышы", Ватаным Татарстан, 1996, 9нчы август.
21. Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова Д. " Мең кыллы күңел", "Мәйдан" 2002, № 5.
22. Сәхапов М. "Хакыйкать йөзе", Казан : Мәгариф, 2005.
23. Татарстан Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, һәм сәнгать институты, "Татар әдәбияты тарихы", 4 нче том, Казан: Раннур, 2001.
24. Татарстан Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, һәм сәнгать институты, "Татар әдәбияты тарихы", 6 нчы том, Казан: Раннур, 2001.
25. Интернет ресурслар: http://adiplar.narod.ru/ http://shigriyat.ru/ http://metodisty.ru/

## “ӨЙРӘТЕРГӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ” АВТОРЛЫК ПРОГРАММАСЫ

## (ата-аналар өчен укыту курсы)

*МБББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Салихова Алсу Нисбәт кызы*

### *Аңлатма язуы*

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы һәм ата-аналар алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максат. Кеше яшьтән үк яхшы белән начарны, түбәнлек белән бөеклекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш. Бишек җырларыннан, ана теленнән башлап, балаларыбыз әйләнә-тирәбездәге бар нәрсәне яратырга тиеш - әти-әнисен, дусларын, үзе уйнап үскән яшел чирәмле урамын, өен, кичке шәфәкъ балкышын, туган якларын калдырып киткән торна тавышларын, яңа чабылган үлән исен ...

Без кырыс, катлаулы заманда яшибез. Яшь буынны тәрбияләүнең төп өлеше ата-ана җилкәсенә төшә. Ә бүгенге көн ата-аналары да бит замана балалары. Лаеклы буын тәрбияләү өчен ата-аналар үзләре дә өйрәтүгә мохтаҗ.

Бу курс укытучыга ата-аналар белән тыгыз элемтә булдырырга, кызыклы һәм иркен атмосферада балаларның проблемаларын хәл итәргә ярдәм итә. Ата-аналарга үз фикерләрен әйтергә, башкаларның фикерен тыңларга, чагыштырырга, анализларга һәм педагогик карашларны баетырга этәргеч бирә. Утырышларның эчтәлеге балалар үсешенең психофизиологик үзенчәлекләрен, гаилә тәрбиясе типологиясен, гаиләдә шәхесара мөнәсәбәтләрне, балада хис культурасы тәрбияләүне, аның әхлакый һәм психик үсешен өйрәнүне күздә тота.

Курс түбәндәге **максаттан** чыгып эшләнде**:**

Ата-аналарның педагогик карашларын баетырга этәргеч бирү.

Курсның **бурычлары** :

- балаларны дөрес кайгырту һәм кайгыртучанлыкка өйрәтергә өйрәтү;
- баланың үзендә ышаныч булдырырга ярдәм итәргә өйрәтергә өйрәтү;
- бердәм эшләр эшләргә өйрәтергә өйрәтү;
- баланы нәтиҗә ясарга, дөрес җавап табарга өйрәтергә өйрәтү;
- баланы проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтергә өйрәтү;
- баланы акчаны дөрес тотарга өйрәтергә өйрәнү;

Бу программа урта звено укучыларының ата-аналары өчен 6 утырышка исәпләнгән. Курсны ике-өч уку елына бүлеп үткәрергә була.

Ул түбәндәге **темалардан** тора:

1.“ Балаларны дөрес кайгырту һәм кайгыртучанлыкка өйрәтү”

2.“ Баланың үзендә ышаныч булдырырга ярдәм итәргә өйрәтү”

3.“Бердәм эшләр эшләргә өйрәтү”

4.“Баланы нәтиҗә ясарга, дөрес җавап табарга өйрәтү”

5.“ Баланы проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтү”

6.” Баланы акчаны дөрес тотарга өйрәтү “

Программаның **актуальлеге** ата-аналарда бала тәрбиясе буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат, бурычлардан чыгып билгеләнә.

***Программаның эчтәлеге***

**I утырыш. Балаларны дөрес кайгырту һәм кайгыртучанлыкка өйрәтү (1 сәг.)**

Кешедә кечкенәдән тәрбияләнә торган матур сыйфат – тирә-юнеңдәге кешеләр, якыннары турында кайгыртучанлык дәрәҗәсен билгеләү өчен мониторинг үткәрү. Тема буенча таблицадагы сорауларга дөрес җаваплар табу. Балаларның сәламәтлеге, материаль ягы белән беррәттән аның күңел тынычлыгы турында да кайгырту. Педагогик ситуацияләр чишү. Коръән сурәләреннән, хәдисләрдән утырыш темасына карата мисаллар карау. Анкета.

**II утырыш. Баланың үзендә ышаныч булдырырга ярдәм итәргә өйрәтү (1 сәг.)**

Бала шәхесенең алга таба үсешен тәэмин итеп, танып-белүгә, тирә-юньне аңларга омтылыш хисен үстерү. Баланың үз-үзенә ышаныч мотивациясе булдыру һәм аны сүндермәү алымнарын өйрәнү. Педагогик ситуацияләр чишү. Баланың үз-үзенә ышаныч булдырырга ярдәм итү өчен эмоциональ һәм физик тотрыклылыкны булдырырга ярдәм итә торган факторларны өйрәнү. Бала фикеренә түземле мөнәсәбәт булдырырга өйрәнү. Сорауларга җаваплар.

**III утырыш. Бердәм эшләр эшләргә өйрәтү (1 сәг.)**

Баланы яшьтән үк күмәк эшләрнең тәмен тоеп, эшләгән эшләрнең нәтиҗәсен күреп горурланырга өйрәтү. Тормышны уртак эшләр белән бизәп, көйләнгән эзгә салу, гадәткә кертү. Ата-аналарның күмәк эшләргә һәм тормышка актив мөнәсәбәте балаларның холкында да чагылуы. Педагогик ситуацияләр чишү. Сорауларга җаваплар.

**IVутырыш. Баланы нәтиҗә ясарга, дөрес җавап табарга өйрәтү (1 сәг.)**

Баланың сәләтен аңлы һәм максатчан үстерергә өйрәнү. Актив эшчәнлеккә һәм аны анализларга этәрүче хәл-вакыйгаларны кабатлап тору уңай нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итүен кәрсәтү. Ниндидер дулкынландырган вакыйга турында бәхәсләшү әдәбе. Башкаларның характерын анализлаганда, үзеңнең дә тискәре якларыңны күрә һәм дөрес нәтиҗә ясый белү:

-үз ялгышларыңа һәм кимчелекләреңә тәнкыйди карау;

-гадәтең нинди, характерың шундый;

-ялкаулыкка каршы көрәшергә;

Педагогик ситуацияләр чишү. Анкета.

**V утырыш. Баланы проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтү (1 сәг.)**

Балада проблемаларны мөстәкыйль хәл итү ихтыяҗына дөрес юнәлеш бирергә өйрәнү. Эчке рухи активлык хәләте булдырып, балага тормышның чын кыйммәтләрен аңлатып, үз карашын, үз идеалын тәрбияләп, тормышта туган проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтү. Бала белән аралашу культурасына өйрәнү. Мондый аралашу тәҗрибәсе баланың да эчке хәрәкәт ихтыяҗын тудыруга омтылыш, теге яки бу вакыйгага карата үз фикерен

тудырып, проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтүен аңлату. Педагогик ситуацияләр чишү. Сорауларга җаваплар.

**VI утырыш. Баланы акчаны дөрес тотарга өйрәтү (1 сәг.)**

Балада экономик үзаң формалаштырырга өйрәнү. Яшәү мәгънәсе акча гына түгел икәнен аңлатырга өйрәнү. Акчаны дөрес тотарга, мөстәкыйль акча эшләргә өйрәтергә өйрәнү. Педагогик ситуацияләр чишү. Анкета.

***Программаның тематик бүленеше***

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| **1 нче утырыш** | **Балаларны дөрес кайгырту һәм кайгыртучанлыкка өйрәтү** | **1**<br>**Теоретик + практик материал** |
| **2 нче утырыш** | **Баланың үзендә ышаныч булдырырга ярдәм итәргә өйрәтү** | **1**<br>**Теоретик + практик материал** |
| **3 нче утырыш** | **Бердәм эшләр эшләргә өйрәтү** | **1**<br>**Теоретик + практик материал** |
| **4 нче утырыш** | **Баланы нәтиҗә ясарга, дөрес җавап табарга өйрәтү** | **1**<br>**Теоретик + практик материал** |
| **5 нче утырыш** | **Баланы проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтү** | **1**<br>**Теоретик + практик материал** |
| **6 нчы утырыш** | **Баланы акчаны дөрес тотарга өйрәтү** | **1**<br>**Теоретик + практик материал** |

***Программаны тормышка ашыру юллары***

Программаның эчтәлеге ата-аналарда бала тәрбиясе буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат, бурычлардан чыгып билгеләнә. Программаны тормышка ашыру юллары һәм методлары төрле : мониторинг, семинар, очрашулар, лекцияләр, диспут-дискуссияләр, сораулыклар-анкеталар, педагогик ситуацияләрне чишү һ.б. Аларны үткәрү ата-аналарның әзерлек дәрәҗәсеннән, түгәрәк занятиеләренең максатыннан тора. Бигрәк тә педагогик ситуацияләр ата-аналарда зур кызыксыну уята. Ата-аналарның бала тәрбиясе белән кызыксынулары артсын өчен, укытучы үткәрү формаларын чиратлаштырып барырга тиеш. Ата-аналар мөстәкыйль рәвештә өйдә төрле чыганакларны өйрәнеп, сорауларга җаваплар табарга тиешләр. Өй эшләренә нәтиҗә укытучы җитәкчелегендә чыгарыла. Эшне оештырган укытучының үзенә дә, беренчедән,

гаилә тәрбиясе мәсьәләләре буенча төп чыганакларны белү мәҗбүри. Икенчедән, үзе дә , чыганаклар белән алдан танышып, тикшеренү эше белән шөгыльләнергә, ата-аналарның өй эше белән кызыксынырга, өченчедән, гаилә тәрбиясе буенча утырышларны оештыручы булырга тиеш.

Курсның темалары актуаль, шунлыктан мисалларны безнең җирлеккә, авыл кешеләренә мөнәсәбәте булганнарын алу уңышлы.

***Көтелгән нәтиҗәләр***

“Өйрәтергә өйрәнәбез ” дигән укыту курсын үткән ата-аналар:

- үз гаиләсенә, балаларына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;
- мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый;
- төрле тормыш ситуацияләреннән чыгу юлларын дөрес сайлый;
- баласы өчен үрнәк булырга омтыла;
- өйрәнгән материалны ныгыта һәм үз белемен күтәрергә тырыша, белемнәрен арттыра;

Бу авторлык прогаммасы ата-аналарга бала тәрбиясенә караган көн кадагындагы мәсьәләләрне тирәнрәк аңларга, өйрәнергә мөмкинлек бирә. Программа буенча эшчәнлек нәтиҗәләре балаларның якыннарын кайгыртуларында, үз-үзенә ышаныч тууда, күмәк эшләр эшли белүендә, нәтиҗә ясый, дөрес җавап таба, проблемаларны мөстәкыйль хәл итә белүендә, акчаны дөрес тотарга өйрәнүендә чагылыш таба.

**Куллану өчен әдәбият**

1. Бондаревская Е.В. Мәгарифне модернизаөияләү шартларында шәхескә якын килү технологиясен куллану.Методист. Фәнни-методик журнал. М.,2003. №2

2. Буйлова Л.Н. Современные педагогические технологии в дополнительном образовании детей. - М., 2000 г.

3. Мәктәптә балалар тәрбиясе. Яңа алымнар һәм яңа технологияләр/ Под ред. Н.Е. Щурковой - М., 1992 г.

4. Воспитательный процесс: изучение эффективности. Методические рекомендации. / Под ред. Е.Н.Степанова. - М., 2000 г.

5. Государственная программа "Патриотическое воспитание граждан Российской Федерации на 2006-2010 годы".

6. Гольдберг В.А. Гуманистическая воспитательная система школы: становление и развитие. - М., 2001 г.

7. Конвенция ООН о правах ребенка.

8. Киммел Т., Клайн Ф., Бенуа С. Воспитание с любовью и логикой. - М.: Центр общечеловеческих ценностей, 1995

9. Минимальный социальный стандарт РФ "Минимальный объем социальных услуг по воспитанию в образовательных учреждениях общего образования".

10. Национальная доктрина образования в Российской Федерации.

11. Сергеева В.П.Зама: Практическое пособие. - М., 2002 г.

12. Сергеева В.П. Заман мәктәбендә класс җитәкчесенең роле. - М., 2000

13. Журналы: “Мәгариф”,"Классный руководитель", "Воспитание школьников", "Справочник классного руководителя", "Воспитательная работа в школе", "Классный руководитель".

14. Интернет ресурслар http://elenasadigova.ucoz.ru

# Мин һәм минем Ватаным

**( дәрестән тыш эшчәнлек буенча 10 нчы сыйныф өчен авторлык программасы,)**

*МБГББУ "Сарман гимназиясе" нең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ханова Нурания Вәзир кызы*

**Аңлатма язуы**

Әхлак тәрбиясе шәхеснең камилләшү һәм үсүендә төп урынны алып торган. Ул гасырлар буена исбатланып расланган. Борынгы грек философы Сенека "Гыйлемлелектә алга китеп тә, әхлак ягыннан артта калган кеше алга китүдән дә бигрәк артка калып яши", -дигән гыйбарәне әйткән.

Әхлак ул - кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган, билгеле бер кыйммәтләрдән торган сыйфат.

Әхлаклылык сыйфатлары алар җәмгыятьтәге үзгәрешләр йогынтысында үзгәрәләр һәм җәмгыятьне дә үзгәртәләр.

Әхлакый кыйммәтләр аерым кешенең яки кешеләр төркеменең рухи кыйбласын, яхшылык һәм яманлыкның асылын ни рәвешле аңлауларын чагылдыра.

Яшь буын гомумкешелек кыйммәтләргә таянып, ирекле, иҗатка сәләтле, яңа сәнгать технологияләренә яраклы итеп тәрбияләнергә тиеш. Бу бурычларны фәкать халыкның педагогикасын тәрбия процессы нигезенә куеп, киң файдаланып кына хәл итәргә була.

Тәкъдим ителә торган эш программасы милли мәктәптә тәрбия бирүнең эчтәлеген үз эченә ала. Тәрбия эчтәлеге, хәзерге чордагы дөньякүләм һәм халыкара интеграция процессларын, илдәге иҗтимагый- икътисади шартларны исәпкә алып, шәхеснең һәрьяклы үсешен тәэмин итү максатын күз алдында тота.

**Әхлак тәрбиясе бирүнең максаты - җәмгыятьтә үз урынын табарлык, әхлаклы, максатчан, үз ватанын яратучы, туган ягы, күренекле шәхесләр турында хәбәрдар булган шәхес тәрбияләү тора.**

**Бурычлар:**

- Балаларны җәмгыятьтәге әхлак кагыйдәләре, әхлак нормаларын белү, даими рәвештә хәбәрдар булуларына ирешү;
- Укучыларда әхлак төшенчәсе турында уңай тәҗрибә булуына ирешү;
- Укучыларның хисләрендә, аңында, тәртибендә әхлаклылык принципларына омтылыш тәрбияләү;
- Ирекле, һәрьяклап камил шәхеснең әхлакый идеалын балаларның тулысынча күзаллавына, шуңа омтылуына ирешү
- татар халкының теле, тарихы, мәдәнияте, милли традицияләре аша милли үзаң формалаштыру;
- укучыларның гомумкешелек кыйммәтләрен тануларына ирешү, аларда гомумкешелек һәм татар милләтенең уңай сыйфатларын тәрбияләү.
- Туган иленә тугрылыклы, ватанпәрвәр тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

Программаны тормышка ашыруда, яшь буын гомумкешелек кыйммәтләргә таянып, ирекле, иҗатка сәләтле, яңа сәнгать технологияләренә яраклы итеп тәрбияләнергә тиеш. Бу бурычларны фәкать халыкның педагогикасын тәрбия процессы нигезенә куеп, киң файдаланып кына хәл итәргә була.

1. Халык педагогикасында әхлак тәрбиясе.
2. Татар халык педагогикасында физик тәрбия.
3. Экологик тәрбия.
4. Акыл тәрбиясе.
5. Зәвык (эстетик) тәрбия.
6. Гореф- гадәтләрнең, йолалаларның, бәйрәмнәрнең урыны.
7. Хезмәт тәрбиясе.
8. Гаилә тәрбиясе.
9. Сәләтле балалар белән эш.
10. Тәрбиягә авыр бирелүче балалар белән эш.
11. Гаиләдә үзара уңай мөнәсәбәт урнаштыру.
12.

**Программаның эчтәлеге**

1. Кешелек җәмгыятенең мораль нигезләре булган гомумкешелек кыйммәтләре, аларның төрләре.

**Милләтпәрвәрлек**

Ватан һәм туган ил төшенчәләренең асылы. Балаларны туган якның үзенчәлекләре белән таныштыру. Яшьләрдә туган илне ярату хисләре формалаштыру. Туган як табигатен саклау һәм яңарту.

2 Милләт буларак яшәүнең төп шарты булган милли үзаң формалаштыру.

**Милләт төшенчәсенең асылы, татар милләте һәм аның үзенчәлекләре**

Бәйсезлеккә, мәгърифәткә омтылу. Моң ярату. Татар халык педагогикасында үзенчәлекле хезмәт һәм һөнәрчелек төрләре.

**Милли үзаң, миллият тойгысы һәи милли горурлык  хисе формалаштыру**

Милли шәхеснең билгеләре, милли үзаң һәм аның состав өлешләре. Үзеңне милләт вәкиле итеп тану. Миллият тойгысы һәм милли горурлык хисе. Татар халкының күренекле шәхесләре. Укучыларны татар халкының күренекле шәхесләре белән таныштыру алымнары, аларны нәтиҗәле куллану.

**Туган телне белү**

Милләт өчен туган телнең әһәмияте. Мәктәптә татар телен өйрәнү һәм аны укыту-тәрбия процессында куллану. Туган телнең дәрәҗәсен күтәрү шартлары.

**Милли мәдәният**

Милли культура һәм милли мәдәниятнең асылы. Рухи һәм матди мәдәният. Иҗатлары кабаттан кайтарылган шәхесләр. Укучыларны мәдәни мирас белән таныштыру, кызыксыну уяту.

**Милли традицияләр.**

Милли традицияләрнең асылы һәм төрләре. Ел фасылларына бәйле элекке бәйрәмнәр һәм йолалар. Татар халкының яңа бәйрәмнәре. Зур эшләрне күмәкләп башкару йолалары. Бәйрәмнәр һәм гореф-гадәтләрне яшьләргә тәрбия бирүдә файдалану. Мәктәп сабантуйлары, Көзге бал, Сөмбелә бәйрәме һ.б. Элекке хәрәкәтле уеннар һәм аларның әһәмияте.

**Үз милләтеңнең тарихы**

Татар халкының тарихы. Татарларның хәзерге чорда таралышы. Киләчәк буынга үз тарихың турында мәгълүмат бирү юллары. Музейлар белән бәйләнеш. Мәктәп, авыл музейларының әһәмияте.

**Үз халкың кабул иткән диннең үзенчәлекләре.**

Татарларның ислам динен кабул итүе. Ислам дине йолалары һәм бәйрәмнәре.

Исламда әхлакый нормалар һәм тыюлар. Хәзерге чорда Татарстанда ислам дине үсеше үзенчәлекләре.

**Ватанпәрвәрлек тәрбияләү**

( Туган илгә, халыкка, телебезгә мәхәббәт тәрбияләү)

Тематик план

| Т/с | Сыйныфтан тыш чара | Максаты | Формасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Бер горурлык хисе | Туган ил, туган тел турында халык авыз иҗатын өйрәнү; халкыбызның күңел бизәкләре белән якыннан танышу, әхлакый-эстетик тәрбия бирү.С. Хәкимнең “Бер горурлык хисе” шигыре | Әңгәмә |
| 2 | Туган ил ул була бер генә! | Ил-көн яңалыклары белән даими танышып бару, хәбәрдар булу. | Әңгәмә. |
| 3 | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы символлары | Символларның җәмгыятьтә тоткан урынын күрсәтү; милли горурлык хисе тәрбияләү | Аралашу, фикер алышу. |
| 4 | Нинди ул Татарстан ? | Татарстанның матурлыгына соклану хисләре уяту, горурлык хисе тәрбияләү. | викторина |
| 5 | Яратам сине, Туган илем! | Туган илгә, Туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү | Төркемнәр дә эш |
| 6 | Россия дәресе | Гимн, герб, флаг турында гомуми күзаллау булдыру | Әңгәмә. |
| 7 | Дәүләт герблары тарихы | Россия, Татарстан герблары тарихы белән таныштыру. Тарихи вакыйгалар белән кертелгән яңалыкларның бәйләнешен күрсәтү | Чыгышлар |
| 8 | Дәүләт әләмнәре тарихы | Россия, Татарстан әләмнәре тарихы белән таныштыру. Тарихи вакыйгалар белән кертелгән яңалыкларның бәйләнешен күрсәтү | Әңгәмә |
| 9 | Дәүләт гимннары. Аларның сүзләре һәм музыкасы | Россия, Татарстан гимннары тарихы белән таныштыру. Тарихи вакыйгалар белән кертелгән яңалыкларның бәйләнешен күрсәтү | Чыгышлар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | Шәхси символлар ясау (уен-дәрес) | Европа, Россия геральдикасының аерым өлешләре турында гомуми мәгълүмт бирү | “Рыцарьлә р турниры уены” |
| 11 | Тамга һәм эмблемалар | Төрле чордагы тамгалар, эмблемалар белән таныу, кызыксыну уяту | Лекция |
| 12 | Ике башлы бөркет | Укучыларны яңа эмблема барлыкка килгәч килеп чыккан проблемалар белән таныштыру | Уен- дәрес |
| 13 | Заманча символлар | Символларны белү өчен шартлар тудыру, эзләнергә этәргеч ясау | Төркемнәр дә эш |
| 14 | Халкыбызның күңел бизәкләре | Халкымның күркәм гадәтләре, үзенчәлекле сыйфатлары белән таныштыру | Уен-дәрес |
| 15 | Халкыбызның күңел бизәкләре | Халкымның күркәм гадәтләре, үзенчәлекле сыйфатлары белән таныштыру | Уен-дәрес |
| 16 | Россиягә хезмәт итәм | Символлар тарихын үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү | Конкурс |
| 17 | Җиңү | Батырлыклар өчен бирелгән орден-медальләрне, герой-шәһәрләрне белү дәрәҗәсен ачыкау | Уен-викторина |
| 18 | Ягез әле, егетләр! | Ватанны склаучылар көненә багышланган чарада актив катнашу | Ярыш |
| 19 | Музыкаль һәйкәлләр | Бөек Ватан сугышы чоры җырларын белү дәрәҗәсен ачыклау. Кызысыну уяту | викторина |
| 20 | Поэзия һәм халыкка тугрылык | Шигырь һәм шагыйрьләрне таный белергә ирешү | викторина |
| 21 | Экстремаль шартларда хәрәкәт һәм тактика | Кыен шартларда үзеңне саклау күнекмәләре формалаштыру | тест |
| 22 | Беренче ярдәм | Бәлагә дучар булган кешегә беренче ярдәм күрсәтү кирәклеген аңлату | Әңгәмә, тест |
| 23 | Милләтебезнең төп сыйфатлары | Милли холык төшенчәсен үзләштерү | Әңгәмә |
| 24 | Буеннар ныклыгы | Буыннар арасындагы чылбырның дәвамчанлыгын аңлау өчен шартлар тудыру | Төркемнәр дә эш |
| 25 | Татарларда тормыш-көнкүреш, хезмәткә мөнәсәбәт | Халык педагогикасында әхлак тәрбиясенең бирелешенә күзәтү ясау | Әңгәмә |
| 26 | Татарларның киенү һәм бизәнү үзенчәлеге | Татар халкының милли сыйфатлары, үзенчәлекләрен белдерү | Әңгәмә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27 | Җиңү алып килгән татар генералы | Алексей Антоновның  бердәнбер “Җиңү ” ордены белән бүләкләнүче булын, батырлыгын төшендерү | лекция |
| 28 | Милли музей – хәтер хәзинәбез | Музейларның әһәмиятен аңлау өчен шартлар тудыру | Әңгәмә |
| 29 | Кыю бул | Әхлакый сыйфатлар формалаштыру | Әңгәмә |
| 30 | Якташ әдипләребез, күренекле шәхесләр | Төбәкнең күренекле кешеләрен белү өчен шартлар тудыру | Чыгышлар |
| 31 | Сарман төбәгендә топонимнар | Топонимнарны белү, аларны өйрәнү өчен җирлек әзерләү | Чыгышлар |
| 32 | Авылымның күркәм кешеләре | Әхлак тәрбиясе бирү, кызыксыну уяту өчен шартлар тудыру | Түгәрәк өстәл |
| 33 | Сарманның табигате, матур урыннары | Горурлык хисе тәрбияләү | Әңгәмә |
| 34 | Исемнәр һәм фамилияләр тарихы | Кызыксыну хисе уяту, әхлак тәрбиясе | Чыгышлар |
| 35 | Иҗади отчет | Нәтиҗәләр ясау, фикер алышу | Түгәрәк өстәл |

## Программаны тормышка ашыру юллары

Программаның эчтәлеге укучыларда ватанпәрвәрлек формалаштыру өчен куелган максат һәм бурычлардан чыгып билгеләнә. Программаны тормышка ашыру юллары һәм методлары, формалары төрле:әңгәмә, түгәрәк өстәл, чыгышлар, викторина, лекция  һ. б. Укучыларга аеруча  әңгәмә, түгәрәк өстәл, викторина үткәрү кызыклы.

Программаны тормышка ашыру өчен  дәрестән соң вакыт каралган. Эшчәнлекнең вакыты 30-35 минутка исәпләнгән.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

1. Җәмгыятьтә үз урынын табарлык, әхлаклы, максатчан шәхес;
2. Туган илеңнен патриоты;
3. Ватаны, кече ватаны турында белүче, күренкле шәхесләрен барлый белә.

## Кулланылган әдәбият


1. Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Гомуми педагогика.  – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2000
2. Әдәплелек дәресләре. Көч һәм рух тамырлары. Казан. Мәгариф, 2000
3. Балаларга үгет-нәсихәт. Казан. 2001.
4. Баязитова Ф. Халык йолалары// Мәгариф, 1993, №2,3, 6,11.
5. Булатов В. Гореф-гадәт, йолаларыбыз.// Казан утлары, 1992, №8.
6. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. Казан “Мәгариф” нәшрияты, 2000.
7. Җәмил хәзрәт Фазлыев. Иманлы бала. Тәрбия турында.  Казан. 2003.

8. Исмәгыйлова С.Г. Исмәгыйлова Ф.М. Тәрбия хәзинәләре. Яр Чаллы, 1992
9. Казыйханов В.С. Әхлак дәресләре. Яр Чаллы, 1998.
10. Казыйханов В. Тәрбияле бала. Казан. 2006.
11. Интернет ресурслар
12. Б. Н. Серов. Государственная символика. Гимн. Герб. Флаг.
13. С. Шәрипова. Кеше. Сәламәтлек. Ислам
14. П. Ф. Куклин, Л. А. Тетушкина, Л. А. Лаврова. Военно-спортивные игры
15. Безнең Мирас. 03.03.2015
16. Гасырлар авазы. ½. 1999

# ТУГАН НИГЕЗДӘН – ГОМУМКЕШЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘРЕНӘ

**(5 – 9 нчы сыйныф җитәкчеләренә тәрбия эшендә методик ярдәмлек)**

*МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәтҗанова Р.Г.*

**Аңлатма язуы**

Яшь буынны мәгърифәтле итү процессында тәрбиягә өстенлек бирү – Россия педагогик традициясенең үзенчәлеге. Әгәр дә тәрбия “Җәмгыятьтә ничек итеп лаеклы яшәргә?” дигән сорауга җавап бирми башласа, торгынлык башланырга, җәмгыять үзенең гуманистик функциясен үтәмәсә, рухи һәм әхлакый үсеш өчен җирлек булдыра алмаска мөмкин.

XXI гасыр шәхесен үстерүдә мәктәп һәм, билгеле булганча, тәрбия зур әһәмияткә ия. Мәшһүр татар гуманисты, мәгърифәтче Каюм Насыйри үз вакытында:”Тәрбия – һәр нәрсәнең ачкычы, аның белән һәр нәрсәне хәл итеп була, ул – кешене кеше итүдә иң дөрес юл”, - дип, бик дөрес язган.

Яшь буында гуманлылык, патриотизм, интернационализм кебек мәңгелек рухи - әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүдә тупланган байлыкны югалтмау, киресенчә, аны үстерү, баету, тәрбия эшендә куллану зур әһәмияткә ия. Балаларга белем һәм тәрбия бирү юлы - туган нигезгә, төбәккә, халыкка, аның гореф – гадәтләренә, йолаларына ихтирам тәрбияләү, моның өчен төрле чаралардан киң һәм нәтиҗәле файдалану, шулар ярдәмендә укучыларда югары әхлак сыйфатлары булдыру, белем алуга, сәламәт яшәешкә омтылыш уяту, үзара һәм башка кешеләр белән иркен аралаша белү күнекмәләре үстерү.

**Программаның максаты:**

туган якны, аның табигатен, авылны, халыкны, аның үткәнен, хәзергесен, халкыбыз һөнәрләрен, иҗатын, үзенчәлеген өйрәнү аша укучыларны рухи яктан бай, иҗади сәләтле, югары мәдәниятле, камил, конкурентлыкка сәләтле шәхес итеп тәрбияләү.

**Бурычлар:**

- әхлакый һәм рухи культура тәрбияләүдә халык педагогикасына таяну, милли – төбәк компонентын куллану;
- милләтара татулык һәм түземлелек сыйфатлары тәрбияләү;
- әйләнә - тирәгә кешелекле мөнәсәбәт тәрбияләү (ветераннар белән хезмәттәшлек, мохтаҗларга ярдәм, хәйрия эшчәнлеге);
- укучыларны туган яктан чыккан күренекле якташлар үрнәгендә тәрбияләү.

**Тәрбия эшенең төп эчтәлеге:**

- әти - әниләр хезмәтен, гаилә йолаларын, халык бәйрәмнәрен, туган якның гүзәл табигатен күрә белү, күренекле якташларның эшчәнлекләре белән танышу, халык җәүһәрләрен өйрәнү, туган төбәк тарихын белү.

Тәрбия эшчәнлеге партнёрлык, тигезлек, үзара хөрмәт, хезмәттәшлек юлы белән түбәндәге принципларга нигезләнеп оештырыла:

- татар халкының рухи байлыгына, гореф – гадәтләренә, үзенчәлекләренә таяну;
- балаларны иҗатка, фәнни хезмәткә тарту;
- туган ягымның байлыгы, матурлыгы, хезмәт кешеләре белән горурлану.

“Туган нигездән – гомумкешелек кыйммәтләренә” дигән принцип нигезендә камил шәхес формалаштыру түбәндәге тәртиптә күзаллана:

| | |
|---|---|
| Мин | исем, фамилиям,күршеләрем,урамым, авылым |
| Ата – ана | исемнәре, һөнәрләре, шөгыльләр |
| Әби – баба | исемнәре, гореф – гадәтләре, тормышлары |
| Туган йорт | нигез, шәҗәрә, җиде буын |
| Урам, авыл, мәктәп | кешеләре, тарихы, халык һөнәрләре, халык җәүһәрләре, экологик халәте |
| Район | тарихы, бүгенгесе, милләтара мөнәсәбәт, мәдәнияте, сәнгате, гомумкешелек кыйммәтләре. |

Программа урта буын сыйныфлары өчен 45 сәгатькә исәпләнеп төзелгән. Туган якны, туган төбәкне өйрәнү билгеле бер эзлеклелектә бара. Программа сыйныф сәгатьләрендә укучыларның

туган як турында күп мәгълүмат туплауына, анда талантлы шәхесләрне барлауына, һәрьяктан камил шәхес формалаштыру һәм иҗади сәләтне үстерүгә ярдәм итәр. Китапка авторлык программасы, тематик план, сыйныф сәгате эшкәртмәләре һәм балаларның иҗади эшләре, өстәмә кулланмалар тупланган.

Һәр сыйныф өчен аерым бүлекләр билгеләнде:

5 нче сыйныф: "Туган якның кадерен бел генә..."

6 нчы сыйныф: "Туган ягым – батырлар төбәге."

7 нче сыйныф: " Без булдырабыз!"

8 нче сыйныф: "Районым алар исеме белән данлы."

9 нчы сыйныф: "Экскурсоводлар мәктәбе."

**ПРОГРАММА (45 сәгать)**

**5 нче сыйныф: "Туган якның кадерен бел генә..." (9 сәгать)**

Туган авылым тарихы

Туган авылымның бүгенгесе һәм киләчәге

Туган авылымның бай табигате

Сарманым – горурлыгым

Сарманыбыз чәчәк ата

Сарманымның истәлекле урыннары

Казан – минем башкалам

Төрле милләт – дус һәм тату

Туган якның экологик проблемалары

"Үткәнен белгән кеше генә, киләчәген белә", ди халык. Бу бүлек туган авылның килеп чыгышы, аның бай табигатен, Сарманның истәлекле урыннары, җитештерү үзәкләрен, башкалам Казанның бай мирасын өйрәнү белән бара. Татарстан - күп милләтле халык, һәр милләт бер – берсенең йолаларын хөрмәт итеп, аларны өйрәнеп яшиләр. Экология – ул тере организмнарның әйләнә - тирә мохит белән үзара мөнәсәбәтләре турындагы фән. Шуңа күрә, без, кешеләр, табигатьне саклау буенча төрле чаралар күрергә тиешбез

**6 нчы сыйныф: "Туган ягым – батырлар төбәге" (9 сәгать)**

Урамыбыз аның исемен йөртә

Дамир Гарифуллин – авылым горурлыгы

Алар сугышның үзен күрделәр

Ватан кушкач кердек утларга

Саклар өчен булса Ватаны, ир – егетләр яклар ил данын

Ак әбиләр – сабыр әниләр

Корыч атым минем кулларда

Без 41 нче ел балалары

Безгә сугыш кирәкми

“Батырлык җирдә ятмый”,- ди халык. Үзеңнең матур эш гамәлләрең, изге эшләрең, Ватанга чын күңелдән бирелгәнлегең белән батырлыклар эшләп, дан казанып була. Тимерхан Сәгъдәтов - әнә шундыйлардан. Сугышның үзен күргән ветераннарыбызны бик тә хөрмәтлибез. Мәктәпне тәмамлап, бүгенге көндә изге бурычларын үтәүче егетләребез белән дә без горурланабыз.

**7 нче сыйныф: “Без булдырабыз” (9 сәгать)**

Җитәкчең нинди, эшең шундый

Каләм алдым кулыма

Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи

Хезмәте каты – җимеше татлы

Тик тормаган, тук торган

Кулыннан гөл тама

Кулымда каләм тибрәтәм

Без булдырабыз

Мәктәбем үзенең җитәкчеләре белән чын күңелдән горурлана, чөнки алар идарә иткәндә мәктәп зур казанышларга ирешә. Туган ягымның зур хәрефтән “Кеше” дип язардай шәхесләре бар, алар турында вакытлы матбугат битләрендә бик күп мәгълүматлар бирелеп килә. Сарманнан чыккан язучыларыбызның китап басмаларын, шигырь җыентыкларын өйрәнәбез, алардан күргәзмәләр эшлибез һәм алар үрнәгендә үзебез дә шигырьләр, бәетләр язабыз.

**8 нче сыйныф: “Районым алар исеме белән данлы” (9 сәгать)**

Театр яктылыкка, нурга илтә

Сандугач теле диләр

Биючегә сүз әйтмәгез

Мин сәнгатькә гашыйк

Спортта көч сынала

Музейларга керсәң

Бил алышмак, көч сынашмак

Һөнәрле кеше – эшле кеше

“Сәламәтлек – зур байлык”, – дибез. Сарман үзенең төрле спорт ярышларындагы уңышлары белән чит илләргә дә билгеле. Районым үзенең театр хезмәткәрләре, җырчылары, биючеләре, сәнгатькә бирелгән кешеләре белән дан тота. Милли көрәш буенча да һәрвакыт алдынгылардан исәпләнә. Һәр кешене һөнәр югары дәрәҗәгә китерер.

**9 нчы сыйныф: “Экскурсоводлар мәктәбе” (9 сәгать)**

Кем ул экскурсовод

Риторика дәресләре

Этикет күнекмәләре

Экскурсовод сөйләме

Экскурсия өчен текст хәзерләү

Библиография

Мәктәп музее

Экспонатлар

Практик эш “ Музейга экскурсия”

Мәктәптә укыганда ук укучылар күп кырлы белем алып чыгарга тиешләр. Шуңа күрә бу бүлек экскурсовод әзерләү өчен дәресләр бирә. Кеше белән аралашырга, киенә белергә, үз – үзеңне тота белү күнекмәләрен, экскурсия үткәрү өчен материал тупларга, текст хәзерләргә, экспонатлар өстендә эшләргә өйрәтә.

**ТЕМАТИК ПЛАН**

**5 СЫЙНЫФ**

| № | ТЕМА | МАКСАТ, ЭШ ТӨРЕ | АҢЛАТМА |
|---|---|---|---|
| | Туган якның кадерен бел генә (5 нче сыйныф) | Туган якның тарихын, табигатен, көнкүрешен өйрәнү,укучыларның фикерләү сәләтен үстерү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү. | |
| **1** | Туган авылым тарихы | Сыйныф сәгате | Туган авылымның килеп чыгышы,борынгы төзелеше,фотоларда сурәтләнеше турында мәгълүмат бирү. |
| **2** | Туган авылымның бүгенгесе һәм киләчәге | Милли бәйрәм | Авылымның хәзерге көндәге тормышы:авылымның тәрбия учаклары, хезмәт урыннары, халкымның милли бәйрәмнәре, йолалары, көнкүреш хезмәтләре белән таныштыру. |
| **3** | Туган авылымның бай табигате | Агроном белән очрашу | Укучыларда туган авылда чыга торган бай табигать хәзинәләре, туфрак уңдырышлылыгы турында күзаллау булдыру. |
| **4** | Сарман – горурлыгым | Сыйныф сәгате | Сарманның тарихы, килеп чыгышы, табигате хакында сөйләшү. |
| **5** | Сарманыбыз чәчәк ата | Сарман буйлап сәяхәт | Сарманның җитештерү үзәкләре,көнкүреш хезмәт үзәкләре, тәрбия учаклары турында әңгәмә үткәрү. |
| **6** | Сарманның истәлекле урыннары | Музей хезмәткәрләре белән очрашу | Музей, китапханә кебек истәлекле урыннар тарихы; алардагы хәзинәләр белән танышу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **7** | Казан – минем башкалам | Сыйныф сәгате | Укучыларда Казанның 1000 еллык тарихы, үткәне һәм бүгенгесе хакында төшенчә булдыру. |
| **8** | Төрле милләт – дус һәм тату | Дуслык кичәсе | Татарстандагы милли төрлелек, төрле милләт халыкларының дуслыгы һәм бердәмлеге турында мәгълүмат бирү. |
| **9** | Туган ягымның экологик проблемалары | Телдән журнал | Табигать пычранулары хакында мәгълүмат биреп, табигатьне саклау – изге бурыч икәнлеген төшендерү. |

**6 СЫЙНЫФ**

| | **ТЕМА** | **МАКСАТ, ЭШ ТӨРЕ** | **АҢЛАТМА** |
|---|---|---|---|
| | Туган ягым – батырлар төбәге (6 сыйныф) | Туган ягымның сугыш һәм тыл батырлары белән танышу,алар турында истәлекләр туплау,укучыларны каһарманнар рухында тәрбияләү. | |
| **1** | Урамыбыз аның исемен йөртә | Музейдагы истәлекле язмалар | Мәктәп музеендагы язмалар белән танышу. |
| **2** | Дамир Гарифуллин – авылым горурлыгы | Хезмәтләрен барлау | Дамир Гарифуллинның тормыш юлы, аның турында язмалар, фотосурәтләргә күзәтү үткәрү. |
| **3** | Алар сугышның үзен күрделәр | Очрашу кичәсе | Бөек Ватан сугышы ветераннары, аларның тормыш юлы, райондагы Советлар Союзы геройлары турында мәгълүмат бирү. |
| **4** | Ватан кушкач, кердек утларга | Язмалар буенча сәяхәт | Чечен, Әфган сугышында булган якташлар, алар турында истәлек язмаларына күзәтү. |
| **5** | Саклар өчен булса Ватаны, ир – егетләр яклар ил данын | Стенд янында әңгәмә. | Хәзерге көндә Ватанны саклау сагында торучы егетләребез, аларның гаиләләре һәм хәзерге хезмәте белән танышу,солдат хатларын уку. |
| **6** | Ак әбиләр – сабыр әниләр | Музейда язма булдыру | Әбиләребезнең тылдагы батырлыклары, аларның хезмәт һәм тормыш юлы турында сөйләшү. |
| **7** | Корыч атым минем кулларда | Кичә | Авылымның кыр батырлары, аларның хезмәт җитештерүчәнлеге, мактаулы исемнәре хакында әңгәмә үткәрү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **8** | Без 41 нче ел балалары | Очрашу кичәсе | Укучыларны сугыш чоры балалары белән таныштыру,алар турында мәгълүмат бирү. |
| **9** | Безгә сугыш кирәкми | Газета чыгару | Тынычлык, яхшылык, яктылык, тыныч тормыштагы изге эшләр турында сөйләшү. |

**7 СЫЙНЫФ**

| **№** | **ТЕМА** | **МАКСАТ, ЭШ ТӨРЕ** | **АҢЛАТМА** |
|---|---|---|---|
| | Без булдырабыз<br>(7 нче сыйныф) | Туган мәктәбемнән чыккан бөек шәхесләр белән танышу, аларның хезмәт юлын яктырту, аларга охшарга тырышу | |
| **1** | Җитәкчең нинди, эшең шундый | Җитәкчеләр турында альбом эшләү | Сарман мәктәбен төрле елларда җитәклләгән директорлар, аларның хезмәт юлы, уңышлары турында төшендерү,. |
| **2** | Каләм алдым кулыма | Сыйныф сәгате | Якташ язучыларның тормыш юлы, иҗатлары белән танышу. |
| **3** | Якташ язучыларның тормыш юлы, иҗатлары белән танышу. | Очрашу кичәсе | Чукмарлы авылында туып үскән күренекле шәхесләребез турында әңгәмә үткәрү. |
| **4** | Хезмәт иясе – хөрмәт иясе | Видео язма | Каташ Каран авылында туып үскән кешеләр турында мәгълүмат алу. |
| **5** | Хезмәте каты – җимеше татлы | Радиотапшыру | Хөрмәткә лаеклы хезмәтчәннәре белән таныштыру. |
| **6** | Тик тормаган, тук торган | Очрашу кичәсе | Авылларның горурлыгы булган күренекле шәхесләре белән танышу. |
| **7** | Кулыннан гөл тама | Күргәзмә | Туган ягымдагы оста куллы һөнәр ияләре, аларның хезмәте турында әңгәмә үткәрү.. |
| **8** | Кулымда каләм тибрәтәм. | Иҗат кичәсе. | Укучыларның иҗат җимешләре (шигырьләре, иншалары, бәетләре) белән танышу. |
| **9** | Без булдырабыз | Сыйныф сәгате | Укучыларның үзләре горурланырдай кешеләре турында әңгәмә үткәрү, портфолиолары буенча сәяхәт уздыру. |

**8 СЫЙНЫФ**

| № | ТЕМА | МАКСАТ, ЭШ ТӨРЕ | АҢЛАТМА |
|---|---|---|---|
| | Районым алар исеме белән данлы (8 нче сыйныф | Райондагы күренекле шәхесләр турында сөйләшү, аларның казанышлары белән танышу, укучыларга эстетик тәрбия бирү. | |
| **1** | Театр яктылыкка, нурга илтә | Сыйныф сәгате | Райондагы театр сәнгатенең тарихы, үсеше, иҗади уңышлары хакында төшенчә бирү. |
| **2** | Сандугач теле диләр | Концертка бару | Районның күренекле җырчылары, композиторлары, гармунчылары турында мәгълүмат бирү. |
| **3** | Биючегә сүз әйтмәгез | Төрле халык биюләре | Районның иң оста биючеләре белән танышу. |
| **4** | Мин сәнгатькә гашыйк | Матбугат битләре буйлап | Сәнгать мәктәбенең уңышлары хакында күзаллау булдыру. |
| **5** | Спортта көч сынала | Экскурсия | “Ялкын” спорт мәктәбенең уңышлары турында сөйләшү. |
| **6** | Музейларга керсәң | Музейдагы язмалар | Район музее турында мәгълүмат бирү. |
| **7** | Бил алышмак, көч сынашмак | Сабантуй бәйрәме | Районымның Республика һәм район күләмендә дан тоткан көрәшчеләре белән таныштыру. |
| **8** | Һөнәрле кеше – эшле кеше | Сыйныф сәгате | Әти - әниемнең һөнәрләре белән горурланам” темасына әңгәмә үткәрү, укучылар белән берлектә “Кем булырга телим?” дигән сорауга җавап эзләү. |
| **9** | Үрнәк гаиләләр | Гаилә бәйрәме | Матур гаилә үрнәкләре турында сөйләшү. |

**9 СЫЙНЫФ**

| № | ТЕМА | МАКСАТ, ЭШ ТӨРЕ | АҢЛАТМА |
|---|---|---|---|
| | Экскурсоводлар мәктәбе (9нчы сыйныф) | Укучыларны экскурсовод вазыйфалары белән таныштыру, экскурсовод итеп әзерләү, үз – үзеңне тоту культурасына өйрәтү. | |
| **1** | Кем ул экскурсовод | Дәрес | Экскурсовод турында мәгълүмат бирү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **2** | Риторика дәресләре | Дәрес | Риторика фәне нәрсәне өйрәнә |
| **3** | Этикет күнекмәләре | Әңгәмә | Әңгәмә үткәрү техникасын, кунакларны каршы алырга өйрәнү, киенү мәсьәләсен карау. |
| **4** | Экскурсовод сөйләме | Әңгәмә | Диалект, жаргонизм төшенчәләрен өйрәнү. |
| **5** | Экскурсия өчен текст хәзерләү | Текст җыю | Экскурсия текстын хәзерләү, экскурсиянең дәвамлылыгын билгеләү. |
| **6** | Библиография | Китапханәгә экскурсия | Библиография турында төшенчә бирү. |
| **7** | Мәктәп музее | Музейга экскурсия | Мәктәп музееның бүлекләре белән танышу, музейның максатлары. |
| **8** | Экспонатлар | Экспонатлардагы язмалар | Бүләк ителгән экспонатлар, фотоэкспонатлар, укучыларның эзләнүдә тапкан экспонатлары турында мәгълүмат бирү. |
| **9** | Практик эш “Музейга экскурсия” | Музейда экскурсия үткәрү | Экскурсиянең максатын билгеләргә өйрәнү, тематик һәм обзор экскурсияләр үткәрү. |